

СУГЫМ ЧОРЫ
Ашаган белми, асраган белә

> 6

ӨЧ ИГЕЗӘК:
«Татар кызларына өйләнәсебез килә»

> 17

ВИНЕРА ГАНИЕВА:
«Мин бик бәхетле хатын булдым»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 172 (28754) | Җомга | 26 ноябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

kzn.ru

КЕМГӘ – КЫШ, КЕМГӘ – ЭШ

УРАМ СЕБЕРҮЧЕЛӘРГӘ КЫТЛЫК НЫК СИЗДЕРӘ

Иртән кемдер эшкә килмәсә, аның юклыгын берәү дә сизмәскә мөмкин, ә менә урам себерүче үз хезмәтен башкармаса, моны барысы да күрәчәк. Кышын бигрәк тә. Бу чорда аларга булган кытлык үзен аеруча сиздерә. Бер каланың гына түгел, бөтен илнең уртак баш бәласе инде ул. Әлегә кар күпләп яумаса да, чын кыш үзен озак көттермәс бит. Эшче куллар җитәме? Район, авыл җирлекләрендә бу мәсьәләне ничек хәл итәләр? «ВТ» шуны ачыклады.

> 5

Ишетми калмагыз

Кәгазь полис бетә

Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе (ОМС) полисын цифрлы форматка күчерү күздә тотыла. Бу хакта Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко белдергән, дип хәбәр итә ТАСС. Министр әлеге үзгәрешнең медицина оешмасына мөрәҗәгать иткәндә эшне тизләтү мөмкинлегене бирәчәген искәрткән. «2022 елдан, федераль ОМС системасында теркәлеп, кәгазьдәге полистан баш тартырга мөмкин булачак», – дигән Мурашко. «Цифрлы» полис, автомат рәвештә, ЗАГС системасында тиешле мәгълүматлар пәйда булгач яки гариза нигезендә булдырылачак. Хәзер исә «Дәүләт хезмәтләре» порталында теркәлгән очракта электрон полис алырга мөмкин.

«Пушкин картасы» тик утырмый

Татарстан «Пушкин картасы» буенча иң күп билет сатылган биш төбәк арасына кергән. Бүгенгә республикада «Пушкин картасы» буенча билетлар сатучы 207 мәдәният оешмасы теркәлгән. 330 меңнән артыграк егет-кыз карта мөмкинлекләреннән файдалана ала. Камал театры, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы, Татар дәүләт филармониясе яшьләргә «Пушкин картасы» буенча билетлар сатуда алдынгы сафларда бара. Районнарда исә Саба, Алексеевск мәдәният йортларына тиңнәр юк. Исегезгә төшерәбез: 3000 сум салынган «Пушкин картасы» 14тән 22 яшькә кадәрге егет-кызларга бирелә. Музейларга, театрлар һәм башка мәдәният учреждениеләренә билет сатып алырга мөмкинлек биргән картадагы акча киләсе елда 5000 сумга җитәчәк.

QR-кодта үзгәреш бар

Коронавируска каршы вакцинаның беренче компонентын ясаткан кешеләргә дә җәмәгать транспортында йөрергә рөхсәт ителде. Татарстан хакимияте республикада QR-код куллануга бәйле үзгәрешләр кертте.

Билгеле булганча, 22 ноябрьдән Татарстандагы җәмәгать транспортында йөрү бары тик вакцина ясату, соңгы ярты елда коронавирус белән авыру турында белешмәсе һәм «медотвод»ы булганнарга гына рөхсәт ителә иде. Транспортта андыйларның QR-кодын тикшерәләр.

Яңа кагыйдәләр буенча, 26 ноябрьдән җәмәгать транспортында:

– ике компонентлы вакцинаның беренчесен яисә бер компонентлы вакцина ясаткан кешеләргә (QR-кодның гамәлдә булу вакыты – 24 көн);

– коронавирустан вакцина ясаткан хәрбиләргә йөрү рөхсәт ителә.

Боларның барысын да медицина оешмалары әзерләгән республика QR-коды раслаячак.

ДУСЛЫКНЫ БЕЛЕГЕЗ, КАЗАННЫ КҮРЕГЕЗ!

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ СОГУД ГАРӘБСТАНЫНА СӘФӘР КЫЛДЫ

Сәфәр

Төп максат «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме утырышында катнашу булса, әлеге чарадан тыш, Президент эшмәкәрләр белән очрашты, бу илдә яшәүче милләттәшләребезнең хәлен белеште һәм Россия мөселманнарының хаҗга бару мөмкинлеге турында фикер алышты.

Бер үк сораулар борчый

Җиддә каласында узган утырышта Рөстәм Миңнеханов Россия Президенты Владимир Путинның сәламләү сүзләрен җиткерде. Путин Россиянең ике яклы мөнәсәбәтләр буенча да, Ислам хезмәттәшлеге оешмасы белән аралашу кысасында да мөселман илләре белән дустанә элемтәләрне үстерүгә зур игътибар бирүен әйткән. «Шунысы мөһим: төбәк һәм глобаль көн тәртибендәге күп кенә актуаль мәсьәләләр буенча безнең позицияләр бик якын», – дигән ул.

Рөстәм Миңнеханов 2005 елдан Россиянең Владимир Путин тәкъдиме белән Ислам хезмәттәшлеге оешмасында күзәтүче булуын искә төшерде. «Безгә үзара мөнәсәбәтләрдәге мөмкинлекләрне активрак кулланырга кирәк. Терроризмга, экстремизмга каршы нәтиҗәләрәк көрәшергә, традицион әхлакый кыйммәтләрне саклау, җәмгыятьнең социаль якланмаган әгъзалары һәм милли азчылыклар турында кайгырту, табигый һәм техноген һәлакәтләргә каршы көрәш, экология кебек юнәлешләрдә эшчәнлекне арттырырга кирәк», – дип сөйләде Татарстан Президенты утырышта. Ул Татарстан мисалына аерым тукталды һәм республикада яшәүче төрле милләт һәм дин вәкилләре арасындагы дустанә мөнәсәбәтне үрнәк буларак тәкъдим ителүен әйтте.

tatarstan.ru

Без тарихта эзлебез!

Рөстәм Миңнеханов Ислам хезмәттәшлеге оешмасы, Ислам үсеш банкы белән уңышлы хезмәттәшлек турында сөйләде. Билгеле булганча, Казанда ел саен «Россия – ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисади саммиты уза. Әле берничә көн элек кенә Казан Ислам хезмәттәшлеге оешмасының 2022 елгы яшьләр башкаласы дип игълан ителде. Киләсе елда тагын бер зур вакыйга көтелә: Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы бәйрәм ителәчәк. Бу уңайдан стратегик караш төркеме утырышы кысасында күргәзмә оештырылды. Рөстәм Миңнеханов 1803 елда Казандагы мөселман типографиясендә беренче басма Коръән бастырып чыгарылуын искә төшерде. Татарстан Президенты бу вакыйганы истәлекле дата буларак билгеләп үтү, шулай ук Казанны «Мөселман дөньясында беренче басма Коръән шәһәре» дип игълан итү тәкъдимен җиткерде.

Җиддәдә Татарстан Президенты Шаһзадә, Король киңәшчесе, Мәккә провинциясе хакиме, Әмир Халед бән Фәйсал Әл Согуд белән очрашты. Рөстәм Миңнеханов Согуд җитәкчелегенең Татарстан делегациясенә һәм хаҗиларга игътибары өчен рәхмәт белдерде. Казанда Согуд Гарәбстанының Генераль консуллыгы ачылса, хаҗилар һәм бу илгә барасы туристларга виза хезмәте күрсәтү тагын да җиңеләер дип көтелә.

Фарсы култыгы Гарәп дәүләтләре хезмәттәшлеге советы Генераль секретаре Нәеф Фәләх Әл Хаҗраф белән очрашуда икътисади хезмәттәшлек турында сүз булды. «Без бу дәүләтләргә «КамАЗ» автомобильләре, вертолетлар, йөк-пассажир судноларын, нефть химиясе продукциясе, нефть-газ чыгару җиһазлары, суыткыч техника, азык-төлек, авыл хуҗалыгы товарлары, хәләл продукция, шулай ук медицина һәм фармацевтика продукциясе җибәрә алабыз. Бу ил компанияләренә безнең республиканың инвестиция проектларында катнашырга тәкъдим итәрбез», – диде Рөстәм Миңнеханов һәм аларны республиканың мөмкинлекләре белән якыннанрак танышу өчен Татарстанга чакырды. Нәеф Фәләх Әл Хаҗраф та ике арадагы мөнәсәбәтләрне мөһим дип саный. «Диннәр төрле булса да, сездәге тыныч тормышның күреп шатланабыз. Ничек яшәргә кирәклекне күрсәтәсез», – диде ул.

Хаҗга юл ачылырмы?

Татарстан Президенты Җиддәдә Согуд Гарәбстанының бизнес вәкилләре белән дә очрашты. Ике арадагы тышкы сәүдә әйләнеше узган ел 18,6 млн доллар тәшкил иткән. 2021 елның 6 ае нәтиҗәләре буенча – 17,1 млн доллар.

Согуд Гарәбстанының хаҗ һәм гомрә эшләре буенча министр урынбасары Габделфәттах бән Сөләйман Мәшәт белән очрашуда бу илгә изге сәфәр кылу мөмкинлеге турында сөйләштеләр. «Кәгъбәне күрү, Мәккәдә булу – безнең өчен зур бәхет. Гомрә кылганда безнең илдән бик күпләрнең хаҗ кылырга теләгәне турында уйладым. Шуңа күрә сездән аларга мондый мөмкинлек бирүне сорамый булдыра алмыйм. Аларга нинди шартлар куела? Вакцинация ясаткан кешеләрне хаҗга җибәрү мөмкинлеге турында алдан ук килешергә телибез», – диде Рөстәм Миңнеханов. Габделфәттах бән Сөләйман Мәшәт бу мәсьәләне һичшиксез тикшерәчәкләрен әйтте.

Гадәттәгечә, сәфәр вакытында Татарстан Президенты чит илдәге милләттәшләребезнең дә хәлен белеште. Хәзерге вакытта Согуд Гарәбстанында 200ләп татар яши, аларның төп өлеше Әр Рияд, Җүбәил, Даммам, Җиддә, Мәдинә калаларында көн күрә. Күбесе – бу илгә соңгы елларда күчеп килгән кешеләр. Нурлат районының Кизләү авылыннан күчеп киткән мөһаҗирләрнең нәсел дәвамчылары да яши. Алга таба алар татар оешмасы төзеп, миллилекне саклап калырга өметләнә.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Волонтер Ольга Шәрифуллина, хәйрия ярдәме оештырып, инде берничә мәртәбә госпитальдә ятучылар өчен кирәкле даруларга акча җыйган. Ул үзе дә коронавирус белән авырып, февраль аенда госпитальдә яткан. Авыруның ни дәрәҗәдә куркыныч һәм мәкерле булуын үз мисалында аңлаган волонтер ханым башкаларга ярдәм итү эшенә алына. Бу юлы ул көндезге стационар мөдире Наталья Сәйфуллинага ялгыз авырулар өчен оекбашлар һәм медицина битлекләре алып килгән. Ольга Шәрифуллина кызы белән бергә COVID-госпитальнең чиста зонасына кәгазь, канцелярия товарлары, бер тапкыр кулланыла торган пеленкалар һәм памперслар алып килгән.
(e-nkama.ru)

Актаныш

Район үзәгендәге поликлиника бинасының икенче катында капиталь төзекләндерү эше тәмамланып килә. Бина ярты гасырга якын элек – 1974 елда төзелгән. Төзекләндерү вакытында хастаханәнең инженер-техник коммуникацияләре алыштырылды, җылыту, су белән тәэмин итү, вентиляция системалары яңартылды, эчке төзекләндерү эшләре тәмамланды. Терапия, хирургия, йогышлы авырулар бүлеге, хатын-кызлар һәм балалар консультацияләре тулысынча ремонтланды. Бу эш «Татарстан стандарты – Дустанә хастаханә» проекты кысасында тормышка ашырыла. Җәй ахырында Актаныш район үзәк хастаханәсендә рентген компьютер томографиясе ачылды. Элек район халкына тикшерелү өчен Чаллыга барып йөрергә кирәк иде.
(«Актаныш-информ»)

Балтач

Районда телләр турында республика законының үтәлешен тикшергәннәр. Җирле башкарма комитет эшмәкәрләрдән хезмәт урыннарының исемнәрен ике телдә язуны таләп итә. Дәүләт карамагындагы объектлар исемнәрен закон кушканча алыштырып бетерде кебек, ә менә кайбер эшмәкәрләрне һаман да закон белән таныштырырга туры килә. Соңгы айларда элмә такталарда, белдерүләрдә киткән хаталарны төзәтү буенча егерме тугыз кибет хуҗасына хәбәр җибәрелгән һәм аларның барысы да төзәтелгән.
(«Хезмәт»)

Кукмара

Манзарас авылында «Батыр» физкультура-сәламәтләндерү комплексы ачылды. Әлеге объект «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» федераль программасы кысасында төзелгән. Комплекс мини-футбол, бадминтон, волейбол һәм зур теннис мәйданчыкларын үз эченә ала. «Безнең бигрәк тә районда мини-футбол, бадминтон юнәлешләрен үстерәсебез килә. Комплекс тулы көченә эшли башлагач, бер дәрес вакытында утыз-кырык бала белән шөгыльләнергә мөмкин булыр, дип уйлыйм. Монда район гына түгел, республика күләмендә ярышлар уздырырлык шартлар бар», – ди «Балаларны сәламәтләндерү, өстәмә белем бирү үзәге» җитәкчесе Нуретдин Зыятдинов.
(«Хезмәт даны»)

КЕМ ДИП ДӘШӘРБЕЗ ИКӘН?

Парламентыбызның егерме җиденче утырышында шактый гаугалы мәсьәләләр каралачагын белә идек. Кайберләренә аерым тукталырбыз. Иң элек республикабызның 2022 һәм 2023–2024 елгы план чорына бюджеты турында бераз әйтеп үтик.

Ел ахырына таба федераль бюджеттан өстәмә акча килү һәм аларны төрле өлкәләргә бүлү – табигый хәл. Тик бу юлы бюджетыбызның чыгым өлеше һәм шуның нәтиҗәсендә бюджет кытлыгы да арту бераз уйландырды. Бюджет, салым һәм финанс комитеты рәисе Леонид Якунин әйткәнчә, бу – минималь хезмәт хакы һәм бюджет системасында эшләүчеләрнең хезмәт хакы артуга бәйле. Әле 2022 елда 3–7 яшьтәге балаларга пособие өчен өстәмә 2 млрд сум бирелачәк. Мәктәпләрнең иминлеген саклауга 1,1 млрд сум тотачаклар. Шулай итеп бюджет кытлыгы киләсе елга 24 млрд 13 млн 734 мең сумга җитәчәк. Парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин залдагы халыкны тынычландырды үзе, илкүләм проектлар өчен Мәскәү акчаны күбрәк бирәчәк икән. Ала каргадан аласын булсын, дип уйлапмы, депутатлар бюджет тирәсендә тавыш чыгармадылар.

Ә менә «Россия субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» дигән федераль закон проектын кабат тикшерә башлагач, түгәрә колакка рәхмәт инде диясе килеп китте. Бу проект быел 9 ноябрьдә Россия Думасында беренче укылышта кабул ителгән иде инде. Төзәтмәләргә уйланыр өчен бер ай вакыт бирделәр. Проект Дәүсоветның Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетында тикшерелеп, тискәре бәя алган иде һәм аны сессия утырышында да кире кактылар. Комитет рәисе Альберт Хәбибуллин кыска гына чыгышында әлеге проектның Россия Конституциясен һәм федерализм принципларын санга сукмавын дәлилләр китереп сөйләде.

Моңа хәтле матбугатта да, башка массакүләм чаралларда да, нигездә, «президент» атамасын бетерү турында язылды һәм сөйләнде. Ә бит мәсьәләнең асылы шактый тирәндә. Комитет рәисен һәм депутатлар чыгышын тыңлап утырганда, кинәт кенә Туфан Миңнуллинны искә төшердем, әлеге закон проекты хакында ул ни әйтер икән, дип уйладым. Соравыма үзем үк җавап таптым да шикелле. Бәлки, Туфан ага Мәскәү тарафына ишарәләп: «Авызларына бармагыңны тыксаң, йә иңбашыннан ук тешләп өзәчәкләр, йә бөтенләй йотачаклар», – дигән булыр иде. Төп Законны санга сукмый торган закон кабул итү үзе үк – дөнья йөзләрендә күрелмәгән хәл. «Федерализм принципларына нигезләнгән» дәүләт дип язылган Россия кай якка таба юл алыр? Унитар дәүләткә кайту турында сүзләр куера башлады инде. 30 ел Президент белән яшәгән Татарстанны ни көтә?

Федераль проект закон рәвешен алып гамәлгә керсә, без «мөстәкыйльлек» дигән сүзне бөтенләй онытырга тиеш булабыз. Хакимият органнарын оештыру, башкарма хакимият җитәкчеләрен билгеләү Мәскәү кулында булачак. Парламентка килгәндә, без федераль законнар эшләүдә катнашудан да ерагаячакбыз, тора-бара бөтенләй катнаштырмаска да мөмкиннәр, димәк, законнар чыгару органының да кирәге калмаячак. Инде болай да ничә еллар буе үз законнарыбызны федераль закон «тәртәсе арасына» кертү белән мәшгульбез. Димәк, башлана башланды булып чыга.

Иң югары вазыйфаи затны да федераль үзәк билгеләячәк. Без аңа кем дип дәшәрбез? Хафиз Миргалимов «башлык» дигән сүзгә гомумән каршы. «Гаилә башлыгы, җирле үзидарә башлыгы, район башлыгы...» – дип санап китте дә: «Президент» атамасы республиканың статусын да билгели», – диде. Хакимият баскычының югары баскычында кем утырырга тиешлеген без яхшырак беләбез, Мәскәүдән торып Татарстан тормышын тулысынча күзаллап булмый ул.

Депутат Марат Галиевнең фикерләре дә кызыклы иде. Аның әйтүенчә, Россия субъектларының хокуклары һәм бурычлары бердәй булырга тиеш түгел. Татарстан – мәсәлән, иң алдынгы технологияләргә нигезләнеп, икътисади үсешкә баручы төбәк. Без дөньяның 166 дәүләте белән социаль-икътисади, мәдәни өлкәдә уңышлы гына хезмәттәшлек итәбез. Бу ил өчен файдага гына бит. Президент идарәсе ул – дәүләтчелек, күп мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итә алу дигән сүз дә, бу да ил өчен файдалы.

Депутатларның кайберләре Татарстанның ислам дөньясы белән бәйланышлары да ил сәясәтенең иң файдалы бер юнәлеше булуын әйтте. Марат Галиев федерализмны аңлау җәмгыятькә авыр бирелә, күрәсең, вакыт кирәк, дигән фикер әйткән иде. «Авыр бирелү» микән бу, әллә аңларга теләмәүме? Икенчесе дөреслеккә күбрәк туры килә кебек.

Татарстан парламенты федераль проектка 18 төзәтмә тәкъдим итә һәм алар аерым каралырга тиеш, ди. Фәрит Мөхәммәтшин тәкъдиме белән бу четерекле эшкә Татарстаннан

Илдар Мөхәммәтҗанов

рәсми вәкил итеп Думадагы депутатыбыз Илдар Гыйльметдинов билгеләнде. «Аның абруе, тәҗрибәсе зур», – диде парламент рәисе. Карап карарбыз инде.

Ә менә санитар-эпидемиология вазгыятенә кагылышлы федераль закон проектын депутатларыбыз хуплады. Берсүзсез дип әйтмибез, бәхәсләр зурдан булды. Таҗвирус пандемиясе уңаеннан төрле чикләүләргә кагыла иде ул. Татарстан федераль проектка кайбер өстәмәләр тәкъдим итә. Яңа таҗвирус инфекциясе таралу куркынычы янаганда гражданнарга төрле чараларда катнашу белән бәйле хезмәт күрсәтү турында алар. Хезмәт күрсәтү дигәнебез гражданнарга вакцинация ясату яки ясатырга ярамау, ковид белән авырганлыгы турында тиешле медицина документларын бирүгә кагыла. Әгәр ул документлар булмаса, 2022 елның 1 февраленә кадәр гражданнар төрле чараларда катнашу өчен яңа таҗвирус инфекциясе булмау турында документ (ПЦР) күрсәтә ала. Ул документның гамәлдә булу вакытын һәм үрнәген Россиянең Баш санитар табибы билгели. (Бу балигълык яшькә җитмәгәннәргә кагылмый.) Закон проектына таҗвирус инфекциясе булу-булмау турында мәгълүматны «Дәүләт хезмәтләре» порталы аша физик затларның «шәхси кабинет»ына җибәрү турында өстәмә дә тәкъдим ителә.

Депутат Алескей Созинов кызыклы гына чагыштыру китерде. «Хәтерлисезме, моннан 10 ел элек автомобильдә йөрүчеләрне иминлек каешы эләктерергә мәҗбүр иттеләр һәм моңа каршы чыгучылар шулай ук табылды. Әмма тора-бара каешның кешене имгәнүдән, үлемнән коткаруын аңладылар. Статистика вакцинаның файдалы икәнен бүген үк раслый, үлүчеләр – нибары 4 процент». Светлана Захарова бәхәсләргә нокта куйды. «Депутат буларак, халыктан миңа да 4 мең мөрәҗәгать керде, барысы да QR-кодка каршы. Шул ук вакытта бүген республика хастаханәләрендә «кызыл зона»да 16 мең табиб эшли. Закон проектын хуплап, аларның барысы да безгә хат язар иде, тик вакытлары юк, кеше гомере өчен көрәшәләр. QR-код кертү – вакытлы чара, кызганыч, битлек, пирчаткәләр тиешле нәтиҗә бирмәде», – диде ул. Ә кеше хокукы бозылу турында сөйләүчеләргә: «Кешене яшәүдән мәхрүм итү хокукын бозу түгелмени?» – диде.

Бик хисле һәм сүзен белеп сөйләде Светлана Михайловна, ул бит – табиб та әле һәм, пандемия бетсә дә, безгә шактый вакыт тернәкләнергә кирәк буласын да онытмады. Менә шул, җәмгыять, үлебезме, калабызмы – үзегез карагыз.

Сүзне куанычлы хәбәр белән тәмамлыйк инде. Утырышта Россия Президентына Яшел Үзәнгә «Хезмәт батырлыгы шәһәре» исеме бирү турында үтенеч кабул ителде. Владимир Владимирович бу үтенечне кире какмас, мөгаен. Һәр ике кешесенең берсе сугышта һәлак булган бу кала хезмәт белән дә җиңүгә зур өлеш керткән.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Дәүләт Советында «Газета-журналларга язылу бүләк ит» хәйрия акциясе оештырылды. Бу чарада парламент депутатлары республиканың социаль учреждениеләре өчен газета һәм журналларга язылды. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Баулының Кырым-Сарай авылында урнашкан интернат-йортында тәрбияләнүчеләргә бүләк итеп «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан», «Шәһри Казан» һәм «Казанские ведомости» газеталарына, шулай ук «Сөембикә» журналына язылды. «Кешеләр вакытлы матбугатны көтеп ала. Дөрес, телевидение дә, радио да бар. Мин бүген Баулы картлар йортын республика басмаларына яздырдым. Өлкәннәр буяу исе аңкып торган газета укырга күнеккән бит, шуның белән яшиләр дә», – диде ул.

ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

Айдар ШӘЙХИН

АРКАСЫНДА – НӘТИҖӘСЕНДӘ

Чикләүләр аркасында өйдә утырам. Чикләүләр нәтиҗәсендә өйдә утырам. Бу җөмләләрнең аермасы бармы? Әллә ни аерма сизелми дә сыман.

Аркада, аркасында сүзләре телебездә бәйлек функциясен башкара. Аның мәгънәсе аңлатмалы сүзлектә менә ничек бәян ителә: «эш-хәлнең башкарылуына сәбәпче, ярдәмче булган затны, предметны, күренешне белдерү өчен кулланыла». Игътибар итегез: зат, предмет, күренеш турында сүз бара. Сүз уңаеннан, *аркасында* сүзенең килеп чыгышы да үзенчәлекле икән. Танылган этимолог Рифкать Әхмәтьянов әлеге сүзне без уйлаган физиологик *арка* белән бәйләми. Ул сүзнең борынгы төрки һәм борынгы монгол телләрендәге тамырын эзләп тапкан: анда *арка* сүзе «төньяк, күләгә, эз, нәтиҗә» дигәнне аңлаткан.

Нәтиҗә сүзе исә гарәп теленнән кергән: «килеп чыгу; токым бирү, уңыш бирү» дигән мәгънәләрне аңлата. Аңлатмалы сүзлектә мәгънәсе «аркасында» сүзе аша аңлатыла: *нәтиҗәсендә – берәр нәрсә аркасында, сәбәпле.*

Аркасында белән *нәтиҗәсендә* арасындагы аерманы төгәл чамалау кыен булырга мөмкин. Монда менә нәрсәгә игътибар итәргә кирәк: *аркасында* сүзе сәбәпне беренче чиратта зат, предмет, күренеш аша аңлата. Кем гаепле? Нәрсә гаепле? Менә мондый сорауларга җавап булар *шуның аркасында* дип әйтеп булыр иде. Шуңа күрә дә күпләр бу сүзне негатив төсмергә ияләр дип фаразлый. *Нәтиҗәсендә* исә бер-бер эш-хәрәкәтнең булуын таләп итә, әмма бу эш исем яки исем фигыль ярдәмендә күрсәтелә.

Мисал буларак, яңгырашы дөресләнгән бер җөмлә: *Ковид аркасында кертелгән чикләүләр нәтиҗәсендә күпләрнең кереме кимеде.*

ҺӘЛАК БУЛУ – ВАФАТ БУЛУ

Һәлак булу сүзе (язылышына да игътибар итегез һәм истә калдырыгыз, һаләк, һәләк, хәләк дип язучылар да бар, болар барысы да – тупас хата) белән бәйле авырлык менә нидә: ул *вафат булу, үлү* сүзләренең синонимы гына түгел. Аны синоним дип әйтеп тә булмый. Асылда гомернең өзелүен аңлатса да, *һәлак булу* сүзе нәкъ менә фаҗигале рәвештә, вакытсыз вафат булу мәгънәсендә кулланыла. Монда сугышта ятып калу гына керми, һәрбер төрле һәлакәттә (менә тагын бер мөһим сүз) гомер өзелү очраклары да бу сүз белән белдерә ала. Әгәр рус телендә аналогия эзләсәк, менә ул: гибель, погибнуть.

Вафат булу белән үлүнең аермасы исә әдәбилектә генә. Беренче сүз әдәбирәк, китапчарак яңгырый. Психологик ягы да бар: үлү сүзе бик куркыныч һәм туры ишетелә, шуңа аның салкынлыгыннан һәм турылыгыннан качу өчен, нәзакәтлерәк формалар *(бакый дөньяга күчте, гомере өзелде, ахирәткә күчте, вафат булды)* кулланыла. Шуңа да кайбер фәнни текстлардагы «Ул 1935 елның 25 апрелендә үлде» сыман җөмләләр кайчак сәер яңгырый, артык гади телдә язылган сыман булып тоела.

Шунысы да бар: китерелгән өч төрле сүз арасында үлү сүзе генә – чын төрки сүз, калган икесе – гарәп алынмалары.

Әйтеп кенә бактым

Булмый дисәң, булмый инде ул

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Беркөнне дустым Альберт шалтырата:

– Абзый, хәлләр ничек?

– Үзең әйтмешли, әйбәт бит.

– Карале, синдә ватык стена сәгате юкмы?

– Юк. Стена сәгатьләре хәзер кемдә генә бар икән соң ул?

– Бар ул, миңа китергәлиләр.

– Әллә коллекционерга әйләндеңме?

– Юк ла, төзәтәм мин аларны, дусларыңа, танышларыңа әйт, китерсеннәр!

Дөресен әйткәндә, Альберттан мондый сүзләр көтмәгән идем, хәтта шаярта, ахрысы, дип тә уйлап куйдым. Чөнки инсульттан соң гәүдәсенең ярты ягы параличланып, инде менә 13 ел инвалид исемен күтәреп йөри ул. Уң кулы, уң аягы эшләми. Бөтен эшне сул кулы белән башкара. Бер кул белән сәгать төзәтеп була микәнни? Шигемне сак кына үзенә дә әйттем. Ә ул: «Булмый дисәң, булмый инде ул», – дип кенә куйды.

Альберт бер ел инвалид коляскасында «яшәде» һәм булмастайны булдырды: кабат аягына басты. Һәр иртәне балконга чыгып, күнегүләр ясый, аннан соң бүлмәгә кереп, велосипед әйләндерә, аннан соң электромассажер белән аяк-кулларына, бөтен тәненә массаж ясый. Тормышка ябышып яту шушы була инде ул.

Заманында тамашачы Альберт Мөхәммәтдиновны талантлы җырчы буларак белә иде. Композитор Илфат Дәүләтшин оештырган «Ак күлмәгем» ансамбленең солисты иде ул. Альберт турында минем телевизион тапшыру да эшләгәнем булды. РТИ (резина техник эшләнмәләр) заводында эшләү өстенә мехчылар сараендагы «Иделкәем» ансамбленә йөрергә дә вакыт тапты. Зәйнәп Фәрхетдинова белән Зөфәр Билалов та шул ансамбльдә вокал серләренә өйрәнеп, зур сәхнәгә менделәр. Инсульт дигәннәре Альберт дусның бөтен планнарын җимерде. Әмма булса да була икән кешедә тормыштан ямь табып яшәргә омтылу.

Инде менә хәзер стена сәгатьләре төзәтә башлаган. Бу кәсепкә ничек кереп киткән? Туган ягы Актанышка кайткач, авылдан бер иске стена сәгате алып килгән булган. Сәгать төзәтүчегә барып: «Күпмегә төзәтеп бирә алисыз?» – дип сораган. «Өч мең сумга», – дигән тегесе. «Сезгә өч мең түләгәнче, шул акчага яңа сәгать алам», – дип, өенә кайтып киткән Альберт. Яңа сәгать алмаган, билгеле, ә искесендә казына башлаган һәм, кем әйтмешли, тәки җиңеп чыккан. «Озынколак хәбәр» тиз тарала бит ул, Альбертка ватык сәгатьләр китерә башлаганнар.

– Акча эшләп буламы соң? – мәйтәм.

– Минем өчен кәкәсеннән бигрәк, мәзәге кыйммәт, бөтенләй башка дөньяда яши башладым, – ди Альберт.

Беркөнне моңа Франциядә эшләнгән сәгать китергәннәр. Дөресрәге, Альберт өйдә юк чакта сәгатьне улы алып калган, нинди икәнен карап тормаган. Башта тыгылырга шикләнсә дә, анысын да төзәткән. Альберт француз сәгате турында кат-кат сөйли, импортный бит ул, ди. Күңелләре үсеп киткән егетнең.

«Сәгать төзәтү» дип әйтү генә җиңел, бит әле аның механизмнарын да алыштырырга туры килә. Монысын да җайлаган Альберт, запчастьларга заказ биреп була икән.

Язмага нокта куяр алдыннан тагын шалтыраттым. Иртәнге күнегүләрен тәмамлаган, хатыны Клавдия белән чөкердәшеп чәйләп алганнар. Күңеле һәрвакыттагыча күтәренке. Әле җитмәсә, тагын бер сәгать китергәннәр. «Хәзер шуңа утырам», – ди.

Кеше үз язмышын үзе тудыра, диләр. Танышларым арасында аяк-куллары исән булып та бөтен дөньясын сүгүчеләр, һәрнәрсәдән зарланучылар да бар. Телефоннан шалтыратсалар, алар белән сөйләшәсе килми, тормышыма бер пычрак килеп керә кебек. Ә Альберт белән сөйләшү – дөнья рәхәте.

Зарланырга яратучыларга кайчак: «Парин урамында бер дустым яши, шуның янына кереп чыгыгыз!» – дим.

– Нәрсәгә? – диләр.

– Гыйбрәт алырсыз, сәгать тә төзәттерерсез.

Аптырап калалар, дәшмиләр. Димәк, әйтер сүзләре юк. Ә минеке бар, шушы язмам белән аңлаган кеше аңларлык итеп әйтеп бактым.

ТИЛЕРҮ,

ЯКИ КАЯ БАРАБЫЗ БЕЗ, КЕШЕЛӘР?

Бу юлларның авторы бүген тагын сәхәр вакытында (таң алдыннан) планетадагы вакыйгаларны карап-барлап утырды. Бүлмәмә Җир шарының төрле почмакларында яңгыраган гыйсъянчылар тавышы бәреп керде, баррикадаларда атылган ташлар «очтылар» һәм болар барысы да реаль режим вакытында диярлек бара.



vk.com

Әйтик, Төркиядә кичтән хәлләр кискенләште, шәһәр урамнары халык белән тулды, полиция гыйсъянчылар яраткан Таксим мәйданын сак астына алды. Төрле сәяси көчләр үзара бәрелеште. Социалистик яңарыш партиясе тарафдарлары илнең иң зур шәһәре урамнары буйлап үтте, Төркиянең эшче партиясен сөючеләр Истанбулдагы Үзәк банк бүлекчәсе янында шауладылар, хөкүмәтнең отставкасын таләп иттеләр. Кемалчылар партиясе (төп оппозиция) бүген (чәршәмбе көн) көндезге сәгать уникедә чираттан тыш җыелыш оештырачак. Босфор университеты студентлары да урамда. Алары идарәче Ак партиягә дә каршы, хакимиятне кулга алырга азапланучы оппозицион кемалчылар партиясенә дә ләгънәтле лозунглар кычкыралар, икесен дә «эксплуататорлар» дип тамгалыйлар. Бу хәлләргә төрек лирасының кискен тәгәрәве этәргеч бирде. Сишәмбе көнне лираның долларга курсы бик нык төбәнәйде дә халык инфляциягә түзә алмыйча урамнарга чыкты. Әнкара, Искешәһәр, Истанбул – барысы да фетнәчеләр тавышыннан тетрәп торды.

Фетнә уты капитализмның иң нык терәге булган илләрдә дә ялкын булып үрли бүген. Чикагода (АКШ) BLM хәрәкәте башлаган фетнәне элекке сенатор Джесси Джексон җитәкләде. Котырган халык төркеме: «Бердәнбер чишелеш – коммунистик революция!» – дип кычкыра. Илдә җинаятьчелекнең күмәк эшләнә торган сәер төре мәйданга чыкты. Дистәләгән кеше берьюлы элиталар өчен ачылган кибетләргә, наркотик сата торган даруханәләргә бәреп керә, киштәдәге товарларны, акча янчыкларын талап чыгып китәләр һәм автомобильләргә утырып юк булалар. Полиция бу хәлләрне онлайн кибетләрдә товар сатучы зур җинаятьчел төркем оештыра дип белдерә, әмма берни дә эшли алмый. Шуңа охшаш хәлләр – халыкның ярдан чыккан елга кебек котырынулары Европада да – Брюссель, Гаага, Амстердам һәм бүтән башкалаларда күзәтелә. Дөнья башкалалары 1917 елның октябрендәге Петроград һәм Мәскәүне хәтерләтә.

Вазгыять бар җирдә дә «Әбигә үч итеп колакны өшеттем» дигән кагыйдә буенча корыла. Кешеләр үзләрен тилергән кебек тота, гомумкешелек принциплары таптала, рәхим-шәфкать дигән нәрсәләр онытыла. Берничә көн элек кенә Хьюстонда 50 мең кешелек концертта кешеләр бер-берсен таптап үтерде һәм имгәтте. Вакыйга сәхнәгә популяр рэпер чыккач башланды, диләр. Халык төркеме нидәндер дулкын булып чайкала, һава җитмәгән кешеләр егыла башлый. Рәсми хакимиятләр әле дә ни өчен концертның бер мизгелдә яшәү өчен көрәшкә әверелүен аңлата алмыйлар. Куркынычсызлык хезмәте офицеры берәүгә ярдәм итәргә омтылгач, муенына кемнеңдер укол кадаганын, шуннан соң аңын югалтып егылуын әйтә. Тамашачыларның берсе, калку урынга менеп, концертны туктатуны таләп итә, әмма калганнар аны тилелектә гаепли, фаҗига фонында җыр дәвам итә. Анда катнашучыларның берсе кешеләрнең тартыша һәм аңнарын югалта башлаулары музыка ешлыгы тәэсирендә булуын әйтә. «Кешеләр акылларыннан шаштылар», – ди.

Әйе, кешеләр бөтен дөньяда үзләрен җенләнгән кебек тоталар. Ә дәүләт җитәкчеләре нишли? «Би-би-си» сайтының бүгенге чыгарылышын ачабыз да Бөекбритания Премьер-министры Борис Джонсон турындагы сюжетка тап булабыз. Джонсон эшмәкәрләр конференциясендә үзен бик сәер тота. Ул Англия икътисады турында сөйләргә тиеш була, әмма теленә ни туры килсә, шуны такылдый. Үзен Муса пәйгамбәр белән чагыштыра, Ленинның цитаталар сибә һәм «Дуңгыз Пеппа дөньясы» дип аталган күңел ачу паркына баруын сөйли. «Мин әлегә кадәр ул парк турында белми идем. Әмма анда миңа ошады. «Дуңгыз Пеппа дөньясы» – минем урыным», – дигән сәер сүзләр әйтә. Газета хәбәрчесенең каналына килгән хәбәрләрдә, Джонсон кәгазьләрен бутап, кирәкле документны таба алмаганлыктан, шулай сафсата сөйләп ташлаган, дигән аклану бар. Гафу итегез, иң түбән интеллектлы адәм баласы да мондый вазгыятьтән шомарак чыга алыр иде, әгәр акылы үзе белән булса инде.

Бер Джонсон гына түгел, дөньяның иң бөек державасы лидеры Байден әфәнде дә чыгышлар ясаганда үзен бик сәер тота. Кичә генә ул бер чыгышын «Цитатаның ахыры» дигән сүз белән тәмамлады. Белгечләр аңлата инде: ул телесуфлер артыннан кабатлый, суфлерны халык күрми, Байден гына күрә, пышылдап торучының әйтергә тиеш булмаган сүзен автомат рәвештә кабатлады гына, диләр. Белгечләр теләсә ни дисеннәр, әмма чыгыш ясаучыларның икесе дә атом-төш чемоданы йөртүчеләр икәнен исәпкә алганда, каз тәне чыга.

Башка лидерларда да бар андый сәерлекләр. Без аларның чыгышлары турында язганда аек акылга сыймый торган урыннарын төшереп кенә калдырабыз, күрмәмешкә салышабыз. Эчтән генә уйлап куясың инде: репэр Трэвис концертыннан чыкты микән әллә дисең. Фикереңне югга салмыйсың инде, әлбәттә, үзеңне тилегә чыгарырлар дип куркасың.

Бүген компьютерны ачуга «Бразилиядә бер хатын үз-үзенә кияүгә чыкты» дигән хәбәргә тап булдым. Сәер бит инде, әйеме? Әмма сәерлек аның белән генә тәмамланмый. Туй күлмәге киеп, кулына чәчәкләр тотып, чиркәү янында фотога төшеп туй үткәргән бу ханым ике ай ярымнан «эчпошыргыч мөнәсәбәтләр»гә чыдый алмыйча «аерылышкан» да. «Инстаграм»да ул үзенең никахы турында игълан иткәч, меңләгән ирләрдән һәм (гафу итегез инде) хатын-кызлардан үзе белән гаилә төзергә тәкъдимнәр алган. Менә аның болары да алай ук гаҗәп үк түгел әле. Бер хатынның акылдан язуы, планетада тагын меңләгән тилергән ир һәм хатынның табылуы мөмкин хәл бит инде. Хәзер социаль челтәрләрдә кемнәр генә юк, иш ишен тапмый калмый. Андый хәлгә төшүдән Аллаһ сакласын, һәркем белән булырга мөмкин. Гаҗәбе һәм берничек тә акылга сыймый торганы – Американың төп газеталарының берсе New York Post газетасының шул юләрләнүне табигый хәл дип санап, җитди игътибарга алып язуы.

Мин кайвакыт танылган совет актеры Алексей Баталовның истәлекләрен укыйм. Бер истәлегендә ул хәзерге кешеләрнең акчага табынуларына борчыла. «Бу – иң көчле сынау, – ди ул. – Кешеләр күз алдында сыналар һәм, шайтан белсен, әллә нәрсәгә әвереләләр. Элек кыш көне авыл урамыннан барганда, кайсы гына өйнең капкасын шакысаң да, сине төн кунып чыгарга кертәләр иде. Ә хәзер оныгы әбисен фатирдан чыгарып ыргыта һәм бушаган 6 метрны никадәр файдалы итеп тотарга мөмкин булуын аңлата. Балаларны аерылышканда бай ирдән күбрәк каерып алу өчен табалар…» Язылган өлеше дә, чынлап та, рәхим һәм шәфкать хисләрен югалтып, кешеләрнең ерткычларга әверелүен аңларлык инде үзе аңларлыкка. Әмма Алексей әфәнде бүген дә исән булса, ковид-гасабилану фонында дәүләткүләм нинди карарлар кабул ителгәнен һәм кешеләрдә акылсызлык пандемиясенең чылбыр реакциясе булып таралуын күрсә, ниләр әйтер иде икән?

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

КЕМГӘ – КЫШ, КЕМГӘ – ЭШ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

«Үзара салым акчасын кулланабыз»

Татарстанның Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы ел башында менә мондый саннар китергән иде: Казанда урам себерүчеләр кирәк кадәреннән – 25, авыл җирлекләрендә 7 процентка кимрәк. Һава торышы явым-төшемнәр белән сөендергән көннәрдә кар көрәү эшләренә җирле халык үзе дә кушыла.

Альмир Зыятдинов Мамадыш районындагы Үсәли җирлеген дистә елдан артык җитәкли. Авыл башлыгы өчен иң авыр чор – кыш. Үсәли җирлегенә алты авыл керә. Бу якларда кар да чагыштырмача күп ява.

– Хәзерге вакытта 1 тонна ягулык алып кайттым. Бер трактор бар. Кышка алдан әзерләнәсең инде ул. Кайбер очракларда иртәнге өчтән үк юлга кузгала. Буран чыга калса, халык та шундук шалтырата башлый. Иң элек мәктәп юлын, хастаханәгә илткән юлны ачмыйча булмый. Аңа сөт машинасы йөри торган юл өстәлә. Вакыты-вакыты белән шартлар дәрәҗәгә дә җитәсең инде, бөтенесенә дә кирәк бит, – ди ул. – Үсәли ягы – Мамадышның гына түгел, республиканың да иң карлы, иң суык җиредер ул. Әле менә Шәмәрдәннән берәү килде. «Мин юлга чыкканда 15 градус салкын иде, сездә 20не күрсәтә», – ди, аптырап. Урыны белән 22 градус та булды әле. Халык исә ишегалларын үзе көри, трактор үтеп киткәннән көтеп ятмый.

Авыл юлларын тәртиптә тоту өчен үзара салым акчасының берникадәр өлеше тотыла. Сала халкы 500 сумнан җыела икән. «Минем карамакта – алты авыл. Якынча 230 мең сум акча китә», – ди Альмир Зыятдинов.

Кайбыч районындагы Кошман авылында да бу эш үзара салым акчасына башкарыла. Халыктан җыелган маяның 160 мең сумы шушы максатка тотыла. Авылдагы крестьян-фермер хуҗалыгы белән килешү төзелгән, юлдагы карны шуларның техникасы чистарта.

– Кошман – зур авыл. Узган атнадагы елларда шактый кар явып алды. Әле районда авыл җирлекләре бу эшкә тотынмаган да иде, безнең авыл иң беренче булып юл чистартырга чыкты. Авыл юлларын чиста тоту – авыл советы җилкәсендә, – ди авыл башлыгы Лилия Сафина. – Буран чыга калса, җаваплы кешесенә шалтыратам, әзер булып торырга кушам. Кешe йөри башлаганчы, юлларны чистартып куя. Үткән кышкы сезонда барлыгы 104 сәгать кар чистартылган. Мәктәп, балалар бакчасы территорияләренә дә трактор кертәбез. Тыкрык-фәләннәрне дә чиста тотарга тырышабыз.

Питрәч районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Шәйхетдинов сүзләренчә, явым-төшемнәрдән соң, беренче чиратта, социаль объектларга керү юллары чистартылачак. Бу – мәктәпләр, балалар бакчалары, хастаханә, кибетләр. Аннары төп һәм башка урамнарга техника керәчәк. Әлеге эшләр өчен җаваплылык авыл җирлекләренә йөкләнгән. Пановка, Питрәч, Коштак, Шигали, Колай авыл җирлекләрендә урнашкан күпфатирлы йортларның йорт яны территорияләрен җиде идарәче компания хезмәткәрләре җыештыра.

Ихтыяҗ арткан

Ноябрь башыннан республикада урам себерүчеләргә булган ихтыяҗ, узган елгы күрсәткечләр белән чагыштырганда, 2,2 мәртәбә арткан. Эшчеләр өчен 200ләп вакансия ачык икән. «hh.ru» хезмәте китергән мәгълүматка ышансаң, урам себерүче хезмәтенә кунакханә, туклану тармагы, ваклап сату, сәүдә өлкәсе, төзелеш оешмалары ихтыяҗ кичерә. 87 процент очракта эш тәҗрибәсе дә таләп ителми. Булачак эшчедән тирә-юньдәге карны көрәү, боз вату, реагент сибү, ишегалдын тәртиптә тоту сорала.

Татарстанда урам себерүчегә 19,5 мең сум күләмдә хезмәт хакы вәгъдә итәләр. Бу – билгеле, уртача күрсәткеч. Шулай да ул узган елгы саннардан 1,2 мең сумга артыграк.

Россия буенча караганда, ноябрь аеннан башлап урам себерүче хезмәтенә эшкә чакырып, 6,8 меңләп вакансия пәйда булган. Бу 2020 елга караганда 89 процентка күбрәк. Кытлык аеруча Мәскәүдә сизелә, анда 1 меңләп эш урыны тәкъдим итәләр. Түләү ягыннан да ил башкаласы алдынгы: дворникка 41,2 мең сум акча вәгъдә итәләр.

Эшче куллар җитмәвен шушы арадагы явым-төшемнәр дә исбатлады. Казан мэриясе мәгълүматларына караганда, шәһәрдә чистартыла торган 22 млн кв. метрның 4 млн кв. метры тротуарларга туры килә. Киләсе елдан бу мәйдан 300 мең кв. метрга артачак – боларга Горький шоссесы дублер юлының 1 нче участогы, «Салават күпере-2» микрорайонындагы юллар, ТАССРның 100 еллыгы магистрале, Тихорецкая урамы буенча Зур Казан боҗрасы участогы, Оренбург трактындагы борылыш төене өстәләчәк.

kzn.ru

ЧИСТАЛЫК ӨЧЕН КЕМ ҖАВАПЛЫ?

ТЕРРИТОРИЯ	ҖАВАПЛЫ
Шәхси йортның коймасыннан алып юлның машиналар йөри торган өлешенә кадәр	Шәхси йорт хуҗасы
Социаль әһәмияткә ия корылмаларга (ФАП, мәдәният йорты, спорт комплексы) илтүче юл	Авыл советы
Җирле әһәмияттәге юл	Авыл советы яллаган подрядчы оешма вәкилләре
Төбәк һәм федераль әһәмияттәге юллар	Юл хуҗалыгы эшчеләре
Торак комплексы яисә күпфатирлы йорт ишегаллары	Торак милекчеләре ширкәте (ТСЖ), идарәче компанияләр яллаган урам себерүчеләр
Административ корылма, белем бирү оешмалары, предприятие мәйданчыклары	Оешма җитәкчеләре

Хәзерге вакытта Казанның төзекләндерү белән шөгыльләнә торган оешма-предприятиеләрендә 600дән артык машина йөртүче-механизатор һәм 550 юл хуҗалыгы хезмәткәре эшли. Тулы сменада эшләү өчен 1300ләп кеше җитми икән. Казан эчендә генә дә берничә йөзләп урам себерүче кирәк.

Ничек кенә булмасын, «тимер ат» тулысынча кешене алмаштыра алмый инде ул. Хәер, моның мөмкин түгеллеген җитәкчелек тә яхшы аңлый.

– Казан шәһәре зур тарихка ия, ул шулай төзелгән ки, хәтта аның кайбер тротуарларын да механик юл белән чистарту мөмкин түгел. Парковка урыннары шыплап тулганын да беләсез, – ди Башкарма комитет җитәкчесенең төзекләндерү мәсьәләләре буенча урынбасары Игорь Куляжев. – Юл хуҗалыгы хезмәтенә урам себерүне җитмәү мәсьәләсен хәл итү өчен берничә мөмкинлектән файдаланабыз. Беренчесе – җәен юл төзекләндерү эшләрендә катнашкан, кышкы чорда эше булмаганнарны дворник буларак эшкә алабыз, икенчесе – техника җәлеп итәбез. Кайбер предприятиеләр мини-тракторлар сатып ала. Алар берничә юл хезмәткәрен алмаштыра. Шулай да, әйткәнемчә, кул көченнән башка мөмкин түгел. Хезмәт хакының аз булуы һәм бу хезмәтнең түбән квалификацияле саналуы тулы күләмдә хезмәткәрләр җәлеп итәргә мөмкинлек бирми.

Ялы да юк, халык та дорфа

Башкаланың төп урамнарын тәртиптә тоту белән шөгыльләнгән бер торак-коммуналь хуҗалыкның төзекләндерү мәсьәләләре буенча директор урынбасары Илнур Бикчәнтәев әйтүенчә, урам себерүчеләргә кытлык кышкы чорда гына түгел, җәен дә сиздерә. «Авыр хезмәт бит инде, ялы юк. Безнең карамакта 18 урам себерүче бар. Моңа өстәп, без төнлә кар көрибез бит әле. Бу вакытка тагын өстәмә 5 кеше ялларга тырышабыз. Ләкин аларны да табу кыен. Күбрәк олы яшьтәгеләр эшли. Яшьләр мондый эш режимына да, хезмәт хакына да риза түгел. Алар төнге сменага килгәли, чөнки акчаны кулга бирәбез. Бөтен нәрсә акча мәсьәләсенә барып тоташа», – дип сөйләде ул.

> Кышкы чордагы хезмәт хаклары 25 мең сум икән. Төнге сменага ялланган урам себерүчеләргә 1,5–2 мең сум акча бирелә. Дворниклар иртәнге 6дан көндезге 3кә кадәр эшли.

Эшчеләргә кытлыкның тагын бер сәбәбе – халыкның битарафлыгы. «Московский» идарәче компаниясе яллаган «Сервисцентр» подрядчы оешмасының директор урынбасары Вадим Гафаров шундый фикердә. Пенсия яшендәгеләр түзәргә мөмкин әле, ә менә 35–40 яшьтәгеләр аларның хезмәтенә карата бик үк әйбәт булмаган мөнәсәбәткә түзәргә әзер түгел. «Ачыктан-ачык әйткәндә, урам себерүчеләр йортта яшәүчеләрнең тупас мөнәсәбәтенә чыдый алмый. Кайберәүләр, чынлап та, үзен бик начар яктан күрсәтә. Әйтик, чүп-чарын да чүп контейнерына кадәр алып бармыйча, подъезд ишеге янында калдыра. Башкалар моның өчен урам себерүчене сүгә. Югыйсә иртә таңнан барысын да җыештырган ул! «Ачык Казан» хезмәтенә зарланып язалар, эшчегә сүз ишетергә туры килә. Барысына да ярап булмыйдыр ул. Шул ук кар яуганда да кемгәдер ап-ак кар ятуы кирәк, кемдер җыештыруны таләп итә. Кемдер ком сипкән өчен рәхмәтле, кайсылары пычрак дип зарлана. Барысын да бер калыпка салмыйм, билгеле, бик яхшы кешеләр дә бар, әмма араларында гел зарланып кына торучылары очрый», – дип сөйләде ул.

Әйтүенчә, урам себерүченең хезмәт хакы күпме мәйданны җыештыруына бәйле.

– Үз карамагына күбрәк йортлар алган саен, хезмәт хакы да күбрәк була. Татарстанда кабул ителгән уртача хезмәт хакыннан да азрак бирмәскә тырышабыз, – дип аңлатты ул. – Чүпләмәгән җирдә генә чисталык була. Әлбәттә, урам себерүчеләрнең хезмәтенә битараф булмаган кешеләр дә бар. Алар бу хезмәткә хөрмәт белән карый, ярдәмләшә, өмәләрдә теләп катнаша.

Төньяк башкаладан үрнәк аласымы?

Күптән түгел Санкт-Петербург администрациясе вәкилләре, Торак комитеты утырышында, «Дворник-шеринг» программасын сынап караячакларын белдерде. Сүз гади кешеләргә территориядән кар җыештыру белән шөгыльләнергә тәкъдим итү турында бара. Күп итеп кар яуган вакытта урам себерүче булып эшләргә ризалашкан кешеләргә 1 мең сум акча түләргә җыеналар. Иртән кар көрисең, кичен кулга акча аласың.

Тайгак юлга каршы үзенчәлекле көрәш алымын Әлмәт районында да кулланалар. Юлларга тоз һәм… кәһвә сибәргә ниятлиләр икән. Район башлыгы Тимур Нагуманов әйтүенчә, сүз иң элек парк һәм сукмаклар турында бара. Әлбәттә, киң юллар өчен мондый ысул бик үк урынлы түгел. Кәһвәханәләр, «Татнефть»нең ягулык станцияләре ярдәмгә килгән.

Халык юл хуҗалыгы хезмәткәрләренең реагент куллануыннан да әллә ни канәгать түгел икән. Тимур Нагуманов әйтүенчә, юл хуҗалыгы хезмәткәрләре юлларны тозсыз гына да эшкәртеп караган, әмма бу тискәре нәтиҗә генә күрсәткән. Тозлы кушылма – мәҗбүри чара. Аның каравы, соңгы елларда Әлмәттә ком сибүдән баш тартканнар. Шуңа да урамнарда чагыштырмача чистарак.

Юлларны чиста тоту мәсьәләсен «эшлекле дүшәмбе» барышында Түбән Каманың яңа мэры Рамил Муллин да искәртте. Искәртеп кенә калмады, тәртип булмаса, хакимият вәкилләре үзләре үк юлны явым-төшемнәрдән чистартырга чыгачагын әйтте. Мондый тәҗрибәнe кулланганы бар икән инде җитәкченең.

Урын кешене түгел, кеше урынны бизи. Арттан комкар өемнәре түгел, чисталык калса, яхшырак шул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ҮГЕЗ САТАМ, КЕМ АЛА?

Авылда сугым чоры башланды. Элегрәк кар яуганны, чын итеп салкыннар башланганны көтеп арыган сала халкы хәзер рәхәткә тиенде. Һәр йортта берничә туңдыргыч. Шуңа күрә ноябрь уртасы үтүгә үк, инде күпләр эре малларын урнаштыра башлый. Быел да искәрмә түгел.

Хәер, авылда хәзер бит мал асрау тәртибе дә элекке кебек түгел. Элек шул бер бозау. Гыйнварда туса да, майда туса да, аны ел ахырына сугым малына әйләндерергә – үзеңә киләсе елга кадәр ашарга җитәрлек ит чыгарлык итеп үстерәсе, симертәсе иде. Капчык-капчык ипи ашатулар да, мич тутырып, мал өчен икмәк пешерүләр дә табигый иде. Ул малкайлар ничек ашап үлмәгән: әле бит төнгә дә бер чиләк тутырып нәрсәдер (пешкән ашлык, бәрәңге) салалар иде. Хәер, башкаларда ничек булгандыр, бездә көзгә кергәч, бозау әллә ничә күбенә иде. «Ярый әле замогы юк, ачып та тутырыр идең», – диләр иде әнигә. Аның каравы бер яше тулмаган бозауларны да дүртәр-бишәр чиләк май чыгарлык итеп симертә иде әни. Ул чакта шунын кадәр май чыгу да бик дәрәҗә иде. Хәзер эч маен алып та тормый күбебез. Эчәкләрен дә караучы сирәк.

Сугымы да хәзер авылда елга бер генә түгел шул. Мал-туарны күп асраган кеше өлгергән берсен озата бара. Итне тулысынча – бездәгечә язсак, дүрт санын (кайдадыр дүрт боты дип сөйләшәләр) бергә җыючы махсус кешеләр бар. Алар иткә бик таләпчән. Әле һәркайсының – үз «закон»ы (сугымчылар бригадасы да аларны белә: итегезне кемгә тапшырасыз, дип сорый). Бер елны бер хатынкыз, майлы итне алырга теләмиләр дип, бөтен маен тунап ташлап бетергән иде. Әле аңа өстәп, башын, үпкә-бавырын «кучтәнәч» итеп, бушка гына алып киткәләр. Бәясе дә шактый ким. Килограммын быел, мәсәлән, 310–315 сумнан, диләр. Кайчакта бер ал, бер арт санны да алырга мөмкиннәр, тик ике алны түгел.

Шәхси хуҗалыкларда бездә бу көннәрдә арт сан үгез итен килограммын 340–350 сумнан сатучылар булды. Тана ите бераз очсызрак йөрсә дә, аның да ал һәм арт саннарга бәяләре барыбер мондый җыючыларга караганда кыйммәтрәк. Берьюлы берничә мал сатканда, үзенә ит калдырасы булмаганда, билгеле, күпләр аларга мөрәҗәгать итә.

Ә үзе өчен санлап алучыларның барысына да арт сан кирәк. Сугым чорында да, гомумән дә, ал саннарны сатып алучы табу бик авыр. Җәй азагында гына зур малның ике ал саны үзебезгә калган иде. «Бу бозауда, – мин әйтәм, – алдан ук чарасын күрәбез: ал саннарга да кеше табабыз, үзебезгә бер арт санны гына калдырабыз». Төрлебез төрле яктан эзләсәк тә, төрле җирләргә белдерүләр бирсәк тә, алгыларны алырга теләүче табылмады. Безнекен генә түгел. Башкаларныкын да алмыйлар. Бу көннәрдә белдерүләр арасында иң күп таралганы да шул: «ал сан ит сатам» булды. Кем берне, кем икене сата. Кем 330 сум дигән, кем 320дән сата. Бәлки... дигән өмет белән без 310 сумнан дип куйдык. Тик шалтыратучы табылмады. Тиресе текмәгән, үсәр дә үсәр, азыгы да бар, дияр идең, үгезнең холкы бик яман. Бер карап чыкканчы, кайгырып торышлы. Шуңа күрә узган елларда бездән арт саннар ала торган кешеләргә хәбәр бирдек, сугымчыларны белештек тә (алары да – «үзебезнекеләр», берничә ел инде шушы егетләргә әйтәбез, чиста-пөхтә дә эшлиләр, итләре дә тәмле була), ал саннарны үзебезгә калдырырга булдык. Теге итләр дә күп булганлыктан, туңдыргычка сыймас инде дип кенә уйладык (өстәп тагын берне аласы да, элекке кебек базга элеп торасы да килми шул).

Иртәгә сугым дигән көнне кич кенә телефоным шалтырый. Күрше районнан бер апа икән. Белдерү буенча шалтырата. Ал санга да риза булучы бар икән, дип аптыраган идем, баксаң, мал-туарны күпләп асраучы (димәк, ал саннарны үзләренә калдыручы) кешеләр булып чыкты. «Берничә сыер асрыйбыз, бозауларыбыз да бар. Сугымга дип калдырган танабыз буаз булып чыкты, бозаулар әле кечерәк, – ди. – Үзебездә малны асраучылар бик аз, шәһәрләшеп беттеләр инде».

...Ә социаль челтәрләрдә әле «Ит сатам» дигән белдерүләр чыгу дәвам итә. Алар янәшәсендә бер, ике айлык, хәтта ун көнлек бозау сатучыларныкы да, «540 килограммлы симертелгән үгез сатам» дигәне дә бар. Тик бер сорау ачык: сатып алучы табылырмы?

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

«ВТ» архивыннан

ИТКӘ ИХТЫЯҖ ЗУР

Быел терлек азыгы бәяләре кыйммәт булгач, ит бәяләре дә артты. Мал тотучылар саны да кимегәч, иткә ихтыяҗ аеруча зур.

Чүпрәле районының Иске Чокалы авылында яшәүче Илдар Усманов та шундый ук фикердә тора. Аның әйтүенчә, халык малларны быел шактый киметкән. Файдасын күрмиләр, ди. Хәер, авылда хәзер сугымга йөрүчесе дә юк, дип әйтерлек.

– Элек алтышар-җидешәр баш мал тотучылар хәзер бер-икегә генә калдырды. Башкача булмый да. Без үзебез дә киметтек. Иптәшемнең аяклары авырта башлады да, терлекләрне азайтырга мәҗбүр булдык. Мине авылдашлар: «Син чалган малның ите тәмле була», – дип, сугымга еш чакыра. Акча өчен йөрмим. Эш беткәч, чәй эчеп чыгабыз. Дөрес, 1 мең сум бирүчеләр дә бар. Аныын да кыенсынып кына алам. Авылда бер-берәңә ярдәмләшеп яшәргә кирәк инде ул. Тиздән өмәләргә йөрүчеләр бөтенләй калмаска мөмкин, – ди Илдар Усманов.

Бәяләргә килгәндә, әле берничә ай элек кенә 280–300 сум булган ит бәяләре бүген 350 сумга күтәрелгән.

– Әле күптән түгел генә Пенза якларына барып чыккан идек. Анда итнең бер килограммын 500 сумнан саталар икән. Терлек асраучылар бездә караганда да азрак, ахры. Элек халык декабрь суыкларын көтеп тора торган иде. Хәзер һәр кешедә зур суыткычлар бар. Шуңа күрә элеккеге сугым чоры дип әйтә торган да түгел. Җәен дә, көзен дә эшкәртәләр. Хәтта кош-кортның да кем кайчан тели, шунда эшен бетерә, – ди ул.

Кукмара районының Бакчасарай авылында да акрынлап сугым чоры башланган. Чулпан Һадиева әйтүенчә, ит бәяләре 340 сумнан башлап 360 сумга кадәр җитә. Шулай ук районда уртача бәя – 350 сум.

– Гадәттә, күрше-тирә авыллар белән сөйләшеп, бер тирә бәяне куябыз. Үзебез малның ал санын – 340 сумга, арт санын 360 сумга биреп җибәрдек, – диде ул.

Аксубай районының Иске Кыязлы авылы фермеры Әлфирә Шакирова сүзләренә караганда, авылларда күңелле мәшәкатьләр чоры. Кемдәдер каз өмәләре гөрли, кемдер малларын эшкәртә.

– Быел сыерларын бетерүчеләр тагын да артты шикелле, – ди ул. – Кемдер мал асрауның файдасын күрми, кемдер өлкәнәйде. Терлекнең алгы боты – 340 сумнан, арткысы 350 сумнан йөри. Без үзебез үстергән терлекләрнең итен эшкәртәбез. Бер ел элек кооператив булдырып, цех ачкан идек. Ярымфабрикатлар эшләп сатабыз. Авылда да сорау бик зур. Вак кына итеп бөккән пилмәннәр, манты, тефтели, фрикадельканы бик теләп алалар. Авылдашлар шәһәрдә яшәүче балаларына унбишәр килограмм пилмән, голубцылар алып җибәрәләр. Шуңа күрә бездә иткә урын табылып кына тора. Малларны да күпләп асрыйбыз. Авырлыгы булса да, эшләр уң баргач, күңел биреп эшлибез.

Зөһрә САДЫЙКОВА

3 декабрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә бүлек мөдире **Сәрия Мифтахова** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

НИЧЕК БЕЛЕП БУЛА?

Дәүләт даруханәләренә ташламага ия кешеләр өчен кирәкле дарулар кайтканмы-юкмы икәнен ничек белеп була?

Тәзкирә ХАФИЗОВА.
Әтнә

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы матбугат хезмәте:
– Бу хакта 264-68-46 номеры буенча Фармация һәм медицина техникасы идарәсенә, 278-82-51 номеры буенча «Таттехмедфарм» оешмасына шалтыратып белешә аласыз.

ТАБИБЛАР ДА ГАЗЕТА УКЫСЫН

Зәйдә халыкка сәламәтлек турында газета тараталар. Аны укыйсың да шаккатасың: бөтен чиргә дәва бар. Табиблар ник укымый икән шул газетаны, нишләп шул киңәшләрне эшләрендә файдаланмыйлар? Файдалансалар, бер чир дә калмас иде бит.

Әнвәр абыегыз.
Зәй шәһәре

РЕДАКЦИЯДӘН
Хөрмәтле Әнвәр абый! Матбугатта басылган рецептлар фәкать киңәш рәвешендә генә бирелә. Алар ярдәмендә чирдән дәваланып булмый. Медицинага таянырга, табигать нигъмәтләреннән файдаланырга, сәламәт яшәү рәвеше алып барырга киңәш итәбез. Сау-сәламәт, озын гомерле булыгыз!

МАЭМАЙ КАЙДАН АЛЫРГА?

Төрле авырулардан тикшерелгән, тәртипкә өйрәтелгән маэмай алыр идем. Тик кыйммәтле бәягә сатып алырга мөмкинлегебез юк. Ярдәм итмәссезме икән?

Зөлфия КАМАЛОВА.
Лаеш районы Столбище бистәсе

Казан мэриясе матбугат хезмәте:
– 28 ноябрьдә Казанның «Крылья Советов» паркында йортсыз калган хайваннарга ярдәм йөзеннән «Дай лапу» хәйрия акциясе уздырыла. Биредә «Зооцентр»да тәрбияләнүче көчекләрдән ошаганын сайлап, өегезгә алып кайтып китә аласыз. Үзәк хезмәткәрләре дүрт аяклы дусларны тәрбияләргә өйрәтәчәк, киңәшләрен бирәчәк. Бу чарада ветеринарлар да катнаша. Мондый чаралар Казанда даими үткәрелеп килә. Җәй азагында ул Горький паркында узды һәм 8 маэмай үзенә яңа хуҗа тапты.

БАЛАЛАРГА БУШЛАЙМЫ?

Кышкы каникулда балаларны музейга алып барырга теләсәк, алардан да QR-код сорамыйлардыр бит инде? Аларга керү түләүлеме, бушлаймы?

Рәйсә САБИРОВА.
Казан

Татарстан Милли музее матбугат хезмәте:
– Татарстан Милли музеена караган оешмаларда QR-кодлар 18 яшьтән өлкәнрәкләрдән таләп ителә. Унсигез яшькә кадәрге балалар музей күргәзмәләре белән QR-кодсыз һәм түләүсез файдалана ала.

АЯК КИЕМЕ КИРӘК

Сезгә ярдәм сорап мөрәҗәгать итәм. Мин – II төркем инвалид, дүрт мәртәбә инсульт кичердем, шикәр чиреннән интегәм. Шуңа күрә махсус аяк киеме бирелә иде. 2021 елга кышкы аяк киеме булмаска мөмкин, диделәр, сатып алырга кушалар. Җәйге аяк киеме була, кышкысы юк, дилә.

Солтания ЛЯМБУШЕВА.
Яшел Үзән районы Әйшә авылы

Татарстан Социаль иминият фондының матбугат үзәге хезмәткәре Ләйсән ҖАББАРОВА:
– Солтания Лямбушева махсус кышкы аяк киеме алучылар исемлегенә кертелмәгән. Без аның үтенечен язып алдык, әлеге хезмәттән баш тартучылар булган очракта, ул әлеге исемлеккә кертеләчәк. Икенче юл да бар. Ул аяк киемен үзе сатып ала һәм компенсация сората ала. Ләкин бу очракта аяк киеме чегында аның ортопедия аяк киеме булуы күрсәтелгән булуы мөһим. Нәкъ менә ортопедия аяк киеме дип искәртелгән чек буенча акчаны кире кайтарып була. Миңа калса, Солтания апа очрагында аяк киемен сатып алып, акчасын кире кайтару отышлырак булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ИКЕНЧЕСЕН САЛДЫРЫРГАМЫ?

Минем соравым вакцинага кагылышлы. Шәхсән үзем коронавирусны вакцина белән генә җиңеп була дип саныйм һәм 84 яшьтә булсам да, «Спутник V» вакцинасын ясаттым. Башта берниндИ йогынтысы сизелмәгән иде, ә менә 7 нче көнне кулның беләзек өлешендә, күпереп-күпереп, кызыл тәрткеләр чыга башлады. Мин инде аны антисептик, спирт сөртеп яндырдым да бугай, алар азып китмәде. Ләкин икеләнәм: вакцинаның икенче өлешен алыргамы миңа? Тагын да көчлерәк аллергия китмәсме икән? Үзебезнең район хастаханәсенә шалтыратсам да, миңа анык җавап бирүче булмады.

Саимә МОРАТОВА.
Чирмешән районы Кара Чишмә авылы

Пульмонолог Нәкыйп КАШТАНОВ:
– Саимә апага икенче вакцина ясатканчы, аллергологка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Сурәтләвенә караганда, аның аллергия кичергән булуы бар. Организм вакцинага алай җавап бирә икән, икенче дозаны алмый тору хәерле.

Табиб-аллерголог Линар МИРЗАҺИТОВ:
– Гадәттә организм вакцинага беренче өч көндә җавап бирә. Шуңа күрә Саимә апада аллергия булса да, вакцина белән бәйле булмаска мөмкин. Шулай ук сезон алмашынганда экзема кебек чирләр дә калкып чыга. Мин аңа дерматолог һәм аллерголог консультациясен алырга киңәш итәр идем. Әгәр тәндә кызыл таплар бар һәм ул бетми икән, башта дәваланырга, аннан соң гына вакцинаны ясатырга кирәк.

Рәхмәт ишетү рәхәт

АНДЫЙЛАР СИРӘК

Узган шимбә көнне Тинчурин урамында узучы авыл хуҗалыгы ярминкәсенә барган идем. Кирәк-яракларны күп алдым. Сөт ризыклары алганда, шул машина янында икенче сумкамны онытып киткәнмен. Шактый озак йөрдем. Бер сумкамның юклыгы өйгә кайткач кына искә төште. Кире бардым. Ни гаҗәп, эше бетсә дә, сөт сатучы егет кайтып китмәгән. Минем сумкамны килеп алуымны көтеп торган. Бик шатландым, әлбәттә. Газета аша шул егеткә рәхмәт белдерәсем килә. Сөт ризыклары – Сабаныкы. Димәк, сатучысы да шул районнан килгән булган. Берәү булса, товары беткәч, кайтып та китәр иде. Ә ул мине көтеп торган. Андый кешеләр хәзер сирәк ул. Эшләре уң булсын, рәхәт яшәсен.

Лариса ИСХАКОВА.
Казан

Әлеге мәрхәмәтле егетне эзләп таптык без. Саба районының Иләбәр авылыннан Райнур Сәфәров булып чыкты ул. Лариса ханымның рәхмәтен җиткердек, бик тә куңеле булды.

«ТАТЭНЕРГОСБЫТ» БЕЛГЕЧЛӘРЕ КИҢӘШ БИРӘ

«Татэнергосбыт» һәрвакыт үз клиентларына якынрак, ә иң мөһиме: аларга файдалырак булырга тырыша. Шуңа күрә электр энергиясен куллануга, килешүләр төзү, «акыллы» исәпләгечләр урнаштыруга бәйле бер генә сорау да, компаниянең элемтә үзәгенә алынгач, игътибарсыз калдырылмый. Иң еш очрый торган сорауларга җавап бирәбез.

:: Электр энергиясе өчен «шәхси кабинет» аша гына түләдем. Бу очракта чекны ничек алырга?
– Түләгәннән соң, «шәхси кабинет»ны теркәгәндә күрсәтелгән электрон адреска чек юллана.

Моннан тыш түләгәннән соң 20 минут үткәч, «шәхси кабинет»тагы «История платежей» битендә түләгәнлекне раслаган чек пәйда була.

:: Башка төбәктә яшим. Казаннан фатир сатып алдым. Анда әле беркем дә яшәми. Фатирның элекке хуҗасының лицевой счеты буенча түлим. Аны үз исемемә ничек дөрес итеп күчерергә?
– «Татэнергосбыт» белән турыдан-туры килешүгә ия булганда, компаниянең үз районыгыздагы клиентларга хезмәт күрсәтү офисына барып яки «шәхси кабинет» аша онлайн форматта күчерергә мөмкин.

Лицевой счетны үз исемегезгә «Татэнергосбыт» офисына барып күчерү өчен, паспортның төп нөсхәсе һәм күчермәсе, ЕГРНнан өземтә яки торак хуҗасы булуыгызны раслаган башка документ кирәк.

«Татэнергосбыт» белән турыдан-туры килешү юк икән, Территориаль участокка (адресы квитанциянең өске уң почмагында күрсәтелгән) барып кына үз исемегезгә күчерә аласыз. Моның өчен шул ук документлар – паспортның төп нөсхәсе һәм күчермәсе, ЕГРНнан өземтә һәм торак хуҗасы булуыгызны раслаган башка документ кирәк.

:: Электрон рәвештәге бердәм түләү документына (ЕДП) ничек язылырга?
✓ «Татэнергосбыт» сайтында «шәхси кабинет»та теркәлергә;
✓компьютерның аскы сул почмагында «Подписка на электронный ЕДП» төймәсенә басарга;
✓килеп чыккан «Заявление на подключение услуги» «тәрәзә»сендә «Я согласен получать электронный ЕПД по электронной почте и отказаться от получения ЕПД в бумажном виде» графасына «галочка» куярга.
✓шуннан соң «Подключить» төймәсенә басарга.

Бу – бушлай хезмәт. Шулай итеп, вакытыгыз, көчегез исраф ителми, экологиягә дә зыян килми (кәгазь исраф ителми).

Хөрмәтле клиентлар! Сорауларыгыз булса, элемтә үзәгенең бушлай телефоны номерын җыеп ***(8-800-200-25-26)****, компания белгечләренә мөрәҗәгать итә аласыз.*

Гөлинә ГЫЙМАДОВА әзерләде

29 ноябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 6.05, 7.05, 8.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 6.35, 7.35, 8.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 10.00, 14.45, 17.30, 22.40 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00, 00.00 «БАБЬЕ ЛЕТО» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
17.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Таяну ноктасы» (продолжение) 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Реальная экономика» 12+
22.30 «Вызов 112» 16+
00.50 «Соотечественники» 12+
01.15 «Черное озеро». Похищение Казанской, 1 часть 16+
01.45 «Путь» 12+
02.00 «Манзара» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.00 «Башваткыч» 6+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 19.10, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.15, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «ВЕРТИНСКИЙ» (S) 16+
23.40 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.00 «Познер» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека»12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов» 16+
21.20 «КЛЮЧ ОТ ВСЕХ ДВЕРЕЙ» 12+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 «ИДИОТ» 12+
04.10 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 11.20, 13.35, 15.55, 22.25, 03.40 Новости
06.05, 21.00, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 Автоспорт. Российская серия кольцевых гонок. Итоги сезона 0+
09.35 «Игры Титанов» 12+
10.30 Зимние виды спорта. Обзор 0+
11.25 «Есть тема!» Прямой эфир
12.25 Специальный репортаж 12+
12.45, 13.40 «КТО ЕСТЬ КТО?» 16+
15.05 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
16.00 «Громко» Прямой эфир
16.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Уфа» – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
18.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Арсенал» (Тула) – «Локомотив» (Москва). Прямая трансляция
21.55 Тотальный футбол 12+
22.30 Церемония вручения награды «Золотой мяч». Прямая трансляция из Франции
00.45 «Есть тема!» 12+
01.05 «СГОВОР» 16+
02.55 Зимние виды спорта. Обзор 0+
03.45 Баскетбол. Чемпионат мира-2023. Отборочный турнир. Мужчины. Исландия – Россия 0+
05.15 «Громко» 12+

НТВ

04.55 Сериал «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ГОРЯЧАЯ ТОЧКА» (S) 16+
23.40 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
01.30 «ПАРАГРАФ 78» 16+
02.55 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.25 Сериал «ПРОВИНЦИАЛ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «Реальная мистика». «Бабайка» 16+
07.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.35 «Давай разведёмся!» 16+
09.40 «Тест на отцовство» 16+
11.55 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Жемчужное проклятье» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «ОПЕКУН» 16+
19.00 «НА ТВОЕЙ СТОРОНЕ» 16+
23.00 «ДЫШИ СО МНОЙ» 16+
02.00 «Реальная мистика» 16+
02.50 «Верну любимого» 16+
03.15 «Порча» 16+
03.40 «Знахарка» 16+
04.05 «Понять. Простить» 16+
05.05 «Тест на отцовство» 16+
05.55 «Домашняя кухня» 16+
06.20 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «22 МИНУТЫ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня 16+
09.25, 01.25 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 12+
13.25, 14.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Наука и война» 16+
19.40 «Скрытые угрозы» 16+
20.25 «Загадки века». «Секретная депортация по-европейски» 12+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «ПРОРЫВ» 16+
02.50 «Выдающиеся летчики. Александр Федотов». Док. фильм 16+
03.30 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 16+

30 ноябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 6.05, 7.05, 8.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 6.35, 7.35, 8.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 14.45, 17.30, 22.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00, 23.30 «БАБЬЕ ЛЕТО» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Рыцари вечности» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 « Тибрәнә җыр дулкыннары » 6+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Динамо» (М) – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
22.30 «Вызов 112» 16+
00.20 «Видеоспорт» 12+
00.45 «Соотечественники». Владимир Вавилов. Дом милосердия 12+
01.10 «Черное озеро». Похищение Казанской, 2 часть 16+
01.35 «Путь» 12+
01.50 «Не от мира сего…» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 22.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 22.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.50 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Тамчы-шоу» 6+
19.30 Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Динамо» (Мәскәү) – «Ак барс» (Казан) 6+
23.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә»(субтитрлы) 12+
03.25 «Оныта алмыйм» 6+
04.15 «Җырлыйк әле!» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.25, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера года. «ВЕРТИНСКИЙ». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 Премьера сезона. «Док-ток» 16+
23.40 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.20 «Эдуард Артемьев. Обыкновенный гений» 12+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым»12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу12+
14.55 «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов» 16+
21.20 «КЛЮЧ ОТ ВСЕХ ДВЕРЕЙ» 12+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 «ИДИОТ» 12+
04.10 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 11.15, 13.35, 15.40, 18.00, 22.35, 04.00 Новости
06.05, 21.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 Специальный репортаж 12+
09.25 «Игры Титанов» 12+
11.20 «Есть тема!» Прямой эфир.
12.20 Все на регби!
12.50, 13.40 «ИГРА В ЧЕТЫРЕ РУКИ» 16+
15.10, 15.45 «БЕССТРАШНЫЙ КОРОЛЬ КУНГ-ФУ» 16+
17.05, 18.05 «ДУЭЛЬ» 16+
19.25 Хоккей. КХЛ. ЦСКА – «Металлург» (Магнитогорск). Прямая трансляция
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Салернитана» – «Ювентус». Прямая трансляция
00.45 «Есть тема!» 12+
01.05 «СГОВОР» 16+
02.55 Гандбол. Лига Европы. Мужчины. «Лемго» (Германия) – «Чеховские Медведи» (Россия) 0+
04.05 Футбол. Чемпионат мира-2023. Отборочный турнир. Женщины. Дания – Россия 0+

НТВ

04.55 Сериал «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный сериал «ГОРЯЧАЯ ТОЧКА» (S) 16+
23.40 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
01.10 Боевик «ПАРАГРАФ 78. Фильм 2-й» 16+
02.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.30 Сериал «ПРОВИНЦИАЛ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Реальная мистика». «Спящая красавица» 16+
07.25 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.30 «Давай разведёмся!» 16+
09.40 «Тест на отцовство» 16+
11.55 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Бессильный ловелас» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «МАМА МОЕЙ ДОЧЕРИ» 16+
19.00 «НА ТВОЕЙ СТОРОНЕ» 16+
23.05 «ДЫШИ СО МНОЙ» 16+
02.05 «Реальная мистика» 16+
03.00 «Верну любимого» 16+
03.25 «Порча» 16+
03.50 «Знахарка» 16+
04.15 «Понять. Простить» 16+
05.15 «Тест на отцовство» 16+
06.05 «Домашняя кухня» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня. 16+
09.25, 01.30 «ТАБАЧНЫЙ КАПИТАН» 6+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25, 14.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Наука и война». Док. сериал. «Битва за недра» 16+
19.40 «Легенды армии». Владимир Бочковский 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
21.15 Новости дня. 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «БЕЗ ПРАВА НА ОШИБКУ» 16+
02.50 «Выдающиеся летчики. Олег Кононенко». Док. фильм 16+
03.30 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ!» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 29 НОЯБРЬ – 5 ДЕКАБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04) Хаталарны барлап, тиешле нәтиҗәләр чыгарырга вакыт. Якын киләчәктә үзегезгә җиңелрәк булсын өчен шулай кирәк. Күңелегез теләгән кыйммәтле әйберне бик отышлы бәядән сатып алу мөмкинлеге чыгачак.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05) Шәхси тормышта – барысы да ал да гөл. Мөнәсәбәтләр дә җылы, матди хәл дә зарланып утырырлык түгел. Дөрес, бурычны түләргә туры килер, әмма бу гаилә бюджетында әллә ни зур чагылыш тапмас.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06) Тырышлыгыгыз әкренләп кенә үз җимешләрен күрсәтә башлаячак. Әкренләп кенә икән, димәк, әлегә өстәмә керемнәр эзләми мөмкин түгел. Күптәнге танышларыгыз, кинәт кенә үзләре турында искә төшереп, юмартлык күрсәтергә мөмкин.

КЫСЛА (22.06 – 22.07) Онытылмаслык чор! Күңелле очрашу-күрешүләргә, искитмәле чараларга чакырырлар. Әлбәттә инде, болар кәеф-рухыгызда уңай чагылыш тапмый калмаячак. Өстәвенә әле бик отышлы тәкъдим дә булачак.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08) Искитәрлек чор түгел: бүген бүләккә сөенсәгез, иртәгә нәрсәгәдер күңелегез сүрелер кебек. Рәхмәтле була белегез, шул чагында барысын да җиңел кичерерсез, дип өйрәтә йолдызлар. Хәйрия юлына басып алырга мөмкин: йөзе белән кире кайтачак!

КЫЗ (24.08 – 22.09) Авызны белеп кенә ачып, саклык белән аралашыгыз: юкса сүзләрегезне бөтенләй кирегә борып сөйләп йөрүчеләр барлыкка килер. Әле тагын үзегезгә басым ясаулары да булып алырга мөмкин. Ә менә сөеклегез белән йомшаграк сөйләшегез – әллә кемләнүнең мөнәсәбәтләргә зур зыян салуы бар хәзер.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10) Эш мәсьәләсе алгы планга чыгар. Начар түгел бу: шулай итеп, сез карьера баскычыннан югарырак күтәрелүгә ирешәчәксез. Әлбәттә инде, гаилә турында да онытмагыз. Юкса үпкәләш чыгарга мөмкин.

ЧАЯН (24.10 – 22.11) Нинди генә эшкә тотынсагыз да, аның уңышлы барып чыгасына шик юк. Бу чорда бер яхшы гадәтегез барлыкка килер. Нәтиҗәдә яңа кешеләр белән танышып, үтә дә өметле планнар белән яши башлаячаксыз.

УКЧЫ (23.11 – 21.12) Бик күп вак-төяк эшләр көтә сезне. Авыр булмаса да, күңелне тынгысызларга җитеп торачак алар. Игелекләр кылу өчен искитмәле дәрәҗәдә әйбәт чор: яхшылыгыгыз үзегезгә йөзе белән кире кайтачак.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01) Тирәгездәгеләргә ярдәм кулы сузу мөмкинлеге пәйда булыр. Аннан файдаланыргамы-юкмы икәнен үзегез хәл итәсез. Мөһим эшләр планлаштырыгыз: барысы да уңышлы килеп чыгачак. Ә менә чыгымнарны әлегә кичектереп тору әйбәт.

СУКОЯР (21.01 – 19.02) Кайбер эшләрегезнең очына чыгу өчен сабырлык кирәк булачак. Җитәкчегезгә берәр нинди эшлекле тәкъдим җиткерү өчен уңайлы чор. Хезмәттәшләрегез арасыннан берәве, саксыз сүзләр ычкындырып, үзегезне үпкәләтергә маташыр.

БАЛЫК (20.02 – 20.03) Йорт мәшәкатьләре күп вакытыгызны алыр. Аның каравы атна ахырында эшегезнең нәтиҗәләренә сөенеп бетә алмассыз. Ярдәм тәкъдим итүчеләр белән саграк булыгыз: аларның ихласлыгы чамалы.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы контроль-хисап органнары советы, озак еллар буе Алексеевск муниципаль районы Контроль-хисап палатасына җитәкчелек иткән

СЕРГЕЕВ
Валерий Ермолаевичның

65 нче яшендә кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

ТЕТА-БЕЛГЕЧ ДИАНА ШӘРИФҖАНОВА:

«КАДАККА БАСКАЧ, БЕР-БЕР АРТЛЫ ХЫЯЛЛАР ЧЫНГА АША БАШЛАДЫ»

Теләкләрем кабул булып, хыялларым тизрәк чынга ашсын дисәң, кадакка басарга кирәк икән! Һәрхәлдә, кешеләрне кадакка бастырып дәвалаучы тета-белгеч Диана ШӘРИФҖАНОВА шулай ди.

Соңгы арада бу күренеш аеруча популярлашып китте. Социаль челтәрләргә карасаң, бүген ике кешенең берсе кадаклы тактага баса, диярсең. Моны үзлегеннән генә эшләп караучылар да, белгеч ярдәмендә махсус әзерләнеп тотынучылар да бар. Берәүләр кадакка кызык өчен генә басса, икенчеләре аның ярдәмендә бик күп чирләреннән котылырга хыяллана. Ничек кенә булмасын, берсеннән-берсе очлы кадаклардан торган мондый такта күпләрне битараф калдырмый.

Язмабыз герое Диана Шәрифҗанова исә кадак терапиясе белән үз юлын эзләгәндә танышкан. «Тета-хилинг ысулын (традицион булмаган медитация алымы. – **Д.Г.**) өйрәнеп йөргән чак иде ул. Аң белән эш итә башладым. Шул ук чорда кадак терапиясе белән дә кызыксынып киттем. Аның ярдәмендә үземне тыңларга, ишетергә өйрәндем. Иң гаҗәпләндергәне шул: кадакка баскач, бер-бер артлы хыяллар чынга аша башлады», – ди белгеч.

Кешенең табан астында 70 меңләп нерв төене бар. Кадакка баскач, шуларның барысы да эшкә җигелә. Диана Шәрифҗанова сүзләренә караганда, кадаклы такта өстендә басып торганда, кешенең бөтен нерв системасы, шул исәптән баш мие дә тонуста була, киеренкелек югала. Кадакка басуның эч катудан интеккән кешегә дә шифасы зур икән. Анда билгеле бер хыял-максатыңны күз алдыңа китереп бассаң, кадаклы тактадан төшкәч, алар бер-бер артлы чынга аша башлый, ди белгеч. «Сәламәтлек өчен кадакка көн саен бассаң да куркыныч түгел. Хыяллар чынга ашсын өчен исә бер тапкыр басу да җитә. Анда басып торганда, кемнеңдер кычкырасы, елыйсы, сөйлисе, җырлыйсы, ниндидер хәрәкәтләр ясыйсы килергә мөмкин. Организм сорый икән, боларның барысын да эшләргә кирәк. Әмма сеансның башыннан ахырына кадәр кадакка басканда күз алдыңа китергән хыялыңны истә тотарга кирәк», – ди Диана.

> **Венер СӘЛМАНОВ, медицина фәннәре кандидаты, табиб-невролог:**
> – Кешенең табан астында бөтен әгъзалар өчен җаваплы биологик актив нокталар бар. Аларга баскалап, бу органнарның эшчәнлеген яхшыртып була дип санала. Кадакка басу методикасының да асылы шуңа таяна. Шуңа күрә кешенең бу ысул ярдәмендә дә шифа алырга теләвенең зыянын күрмим. Әмма кадакка басар алдыннан иң элек табиб белән киңәшләшергә кирәк. Хроник авырулары булган кешеләргә бигрәк тә. Организмында ялкынсыну башланган, йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан интеккән, яман шеш диагнозы куелган кешеләргә кадакка басу тыела.

Кадакка басу уен эш түгел. Йөрәк мускулының хәлсезлегеннән, эпилепсиядән интеккән кешеләргә бу эш катгый тыела. Инсульт, инфаркт кичергән кешеләргә дә кадакка басудан тыелып тору хәерле. Йөкле хатын-кызларга, исерткеч эчемлек кулланучыларга да кадакка басу тыела. «Бу эшкә белгеч ярдәмендә махсус әзерлек белән тотынырга киңәш итәр идем. Аны үзлегеңнән генә башкарырга тырышу куркыныч. Кадакка баскач, беренче өч минутта кеше кискен авырту тоя. Аннары акрынлап ияләнә төшә. Кадаклы тактага беренче тапкырдан ук мамык мендәргә баскан кебек җиңел генә атлаучылар да бар», – ди Диана Шәрифҗанова. Кадакка басу ярдәмендә күңелдә яшеренеп яткан хисләрне чыгарып, ачу, көнләшү кебек кичерешләрдән дә котылырга мөмкин икән.

Исеңдә тот!

✓ Ун минут кадакта басып тору 15 чакрым җәяү йөрүне алыштыра.

✓ Кадакта басып тору организмны энергия белән тәэмин итә. Шуңа күрә кышкы салкында тиз туңучылар, кадакка баскач, бу халәтеннән дә арына.

✓ Кадакка басу матдәләр алмашын яхшырта. Моның белән даими рәвештә шөгыльләнгән кеше артык авырлыктан интекми.

Тест

Организмыгызга магний җитәме?

1. Кулларыгыз һәрчак корымы?
- кулларым һәрчак дымлы була (2 балл)
- әйе (0)
- кайчан ничек инде (1)

2. Аз калорияле диеталарда утырасызмы?
- әйе, даими рәвештә (2)
- булгалый (1)
- беркайчан утырганым юк (0)

3. Кузаклы үсемлекләрне (ногыт борчагы, борчак, ясмык) айга бер тапкырдан да азрак ашыйсызмы?
- төрлечә була (1)
- әйе (2)
- юк, кузаклыларны һәрдаим ашыйм (0)

4. Шпинат, яшел ногыт борчагы кебек яшелчәләрне атнасына 3 тапкырдан азрак ашыйсызмы?
- әйе (2)
- юк (0)
- кайчан ничек туры килә (1)

5. Кыздырыр алдыннан бөрәңгене суда озак тотасызмы?
- әйе, берничә сәгать суда тотканнан соң гына кыздырам (0)

- чистартуга ук кыздырам (2)
- төрлечә була (1)

6. Төнлә белән аягыгызны көзән җыерганы бармы?
- юк (0)
- бик еш (2)
- кайчак булгалый (1)

7. Ризык сайлаганда составында минераль матдәләр булу-булмауга игътибар итәсезме?
- һичшиксез (0)
- составын карарга оныткан чаклар да була (1)
- беркайчан игътибар иткәнем юк (2)

НӘТИҖӘ

0–10 балл. Организмыгызда магний җитәрлек. Дөрес туклану һәм сәламәт яшәү рәвеше алып баруыгыз нәтиҗәсе бу!

10–15 балл. Магний запасы акрынлап кими бара! Соңгы арада стрессларга тизрәк бирешә башлавыгызны үзегез дә сизгәнсездер. Шуңа күрә тынычлык сакларга тырышыгыз, организмга физик яктан авырлык китерүдән дә сакланыгыз. Магнийга бай кешью, миндаль, фундук, кыздырылган көнбагыш, карабодай ашарга һәм минераль су эчәргә киңәш ителә.

15–24 балл. Организмыгызга магний җитми. Вакытында чарасын күрмәсәгез, бу ашказаны, йөрәк эшчәнлегенә зыян салачак. Көзән җыеру да күзәтелергә мөмкин. Мондый очракта кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итегез!

КАРТАЙТА ТОРГАН 4 РИЗЫК

Белеп тор!

▶ **Шикәр.** Организмда шикәрнең чамадан тыш күп булуы аркасында, тән тиресе сыгылмалылыгын югалта. Бу исә күпләп җыерчыклар пәйда булуга китерә. Моннан тыш шикәр гәүдә авырлыгын да арттыра, буыннар сызлавы, баш авыртуга сәбәпче була.

▶ **Трансмайлар.** Фри бәрәңгесе, ярымфабрикатлар, әзер камыр ризыкларында очраучы бу майларны ризык озак саклансын өчен кулланалар. Шул ук вакытта ул кан тамырларын тыгызлатуы аркасында тән тиресен дә картайта.

▶ **Тоз сәламәтлек өчен файдалы санала.** Әмма күпкә китсә, ул иң элек организмның хәлсезләнүенә китерә. Тоз күп ашаган кеше ничек кенә ял итсә дә, арыган кыяфәттә йөри. Чамадан тыш тозлы ризыклар ашаган кешенең бөерена да зыян килә, кан басымы күтәрелә.

▶ **Кәһвә.** Күпкә китсә, әлеге эчемлек организмга су җитмәүгә китерә. Нәтиҗәдә тән тиресе яргалана, җыерчыклар пәйда була. Кеше үз яшеннән күпкә олырак күренә. Шуңа күрә көнгә күп дигәндә ике чокыр кәһвә эчәргә кирәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ЯСАЛМА ЧЫРШЫНЫ НИЧЕК САЙЛАРГА?

Яңа ел бәйрәмнәренә дә күп калмый. Кибет һәм базарларда халык, мәш килеп, чыршы сайлый. Әлбәттә, чын чыршыга өстенлек бирүчеләр дә бар. Әмма ясалма чыршы сайлаучылар күбрәк, ди сатучылар. Дөрес сайланган ясалма чыршы әллә ничә ел куандырып торачак һәм шактый гына акчаны янга калдырачак бит. Чыршы сайлау буенча консультант Гүзәлия ВАФИНА кайбер киңәшләрне истә тотарга кушты.

pixabay.com

● Сертификаты бармы?

Беренче чиратта ясалма чыршының янгын куркынычсызлыгы сертификатлары булуын тикшерегез. Әгәр тартмада тиешле билге юк икән, сез чыршының янып киту ихтималын тикшереп карауларын сорый аласыз. Әгәр дә ул дөрләп яна башласа, аны алмавыгыз хәерле. Әлбәттә, кибеттә моны эшләү мөмкин булмаса да, базардан алганда тикшерергә мөмкин.

● Кем җитештергән?

Россиядә җитештерелгән чыршылар сыйфатлы һәм бәяләре дә кулай булу белән аерылып тора. Кытай җитештерүчеләре икенчел чималлар кулланып эшләгәнлектән, аннан кайтарылган чыршының ят исе булырга мөмкин һәм куллану вакыты азрак булачак. Гадәттә, алар формаларын да тизрәк югалталар. Европадан кайтарылган ясалма чыршылар шулай ук барлык сыйфат стандартларына туры килә. Аларның бәяләре безнекеләрдән кыйммәтрәк.

● Нинди ысул белән ясалган?

ПВХ чыршылар иң кулай бәяле һәм матур булулары белән аерылып тора. Аның энәләре йомшак һәм чәнчеми.

Кылсыман энәләрдән ясалган чыршылар наратка охшап тора. Аның ботаклары бик купшы һәм күләмле.

Коеп ясаганнары чын чыршыга бик охшаган. Мондый резинасыман чыршылар алда әйтелеп үткәннәргә караганда озаграк хезмәт итә. Алар экологик яктан чиста, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә иң туры килә торганы.

● Чыршының зурлыгы нинди булырга тиеш?

Чыршы сайлаганчы, аны кая урнаштырасыгызны уйлагыз. Бәйрәм гүзәленә сез күпме мәйдан бирергә әзер? Кечкенә бүлмәләр өчен өстәл чыршылары сайларга мөмкин. 5 метрга кадәрге биеклектәге чыршылар зур йортлар, заллар өчен яхшы булыр, ә шәһәр фатирлары өчен 2,5 метрга кадәр озынлыктагыларын сайларга киңәш ителә.

● Ныклыгы ничек?

Чыршы алганда аның каркасына да игътибар итегез. Ул авып китәргә һәм бөгелергә тиеш түгел. Ә ботаклардагы ылысларын учыгызга алып ышкып карагыз, коелмаса, димәк, чыршы ышанычлы. Ботакларның сыгылмалылыгын тикшерү өчен бөгеп карагыз. Әгәр ул бераздан үз формасына кайтса, аңа эленгән уенчыкларны да чыдатачак дигән сүз.

● Ничә елга җитәчәк?

Гадәттә сатып алучыларга чыршының ничә ел хезмәт итүен дә игътибарга алырга кирәк. ПВХ чыршылар 10 елга җитә. Ә коеп ясалган чыршыларның гомере – 50 елдан артык.

Кыскасы, чыршыны әлеге киңәшләрне истә тотып сайласагыз оттырмассыз.

Тәмле булсын!

Гөмбәле койка

Кирәк: *1 данә сыер аягы, 2 баш суган, 2 тырнак сарымсак, 60 г маринадланган гөмбә, 1 данә пешкән кишер, тоз, борыч һәм яшел тәмләткечләр.*

Сыер аягын кәстрүлгә сыярлык итеп бүлгәләп, тоз салган суда акрын утта ите сөягеннән аерылырлык булганчы (3–4 сәгать) кайнатабыз. Су 1:3 күләмендә салына. Пешкән итләрне алып, шулпаны сөзәбез. Аннары итне турап, кабат шулпага салып, 15–20 минут кайнатып алабыз.

Шулпаны ите белән бергә койка өчен әзерләнгән савытка салабыз. Туралган сарымсак, кишер, гөмбә, борыч салып, суыткычка куябыз.

Белеп тор!

ДӨГЕ ҖЫЛЫТА

Бик нык туңганда, аяк-кулны җылытуның бик ансат бер ысулы бар. Моның өчен чүпрәк капчыкка яки синтетика булмаган юка оекбашка дөге салып, микродулкынлы мичтә 2–3 минут җылып алырга кирәк. Әлеге җылы дөгене учта тотарга яки табанга куеп торырга була. Дөге суынып китсә, тагын җылытып алырга мөмкин.

Лайфхак

КЫРЫККАРТА ЧИСТАРТАБЫЗ

Сугым чоры башланды. Кемнәрдер хайванның эчәкләрен ташласалар, кайберәүләр алардан тәмле ризыклар әзерли.

Халык телендә «түбәтәй», «кырыккарта» дип йөртелүче әгъзаларны ансат кына да чистартып була икән.

Кырыккарта чистарту буенча лайфхак белән Зөлфия Гыйлемҗанова бүлеште.

– Карда таптап, чайкап алганнан кырыккарта белән «түбәтәй»гә ике-өч уч тирәсе сода белән тоз салып, берәр сәгать тотарга. Шулай иткәннән соң аның кырыла торган өлеше кубып кына төшәчәк, ә үзе ап-ак булып калачак.

Шулай ук аңа 9 процентлы уксус салып тоткан очракта да бик тиз чистарачак.

Остаханә

5 минутта бүләк әзер!

Тиздән Әниләр көне җитә. Балаларга әниләренә тиз генә бүләк ясау ысулын тәкъдим итәбез.

Моның өчен ике ягы да бер төсле коңгырт кәгазьгә кулыбызны куеп, рәсемдә күрсәтелгәнчә, карандаш белән йөртеп чыгабыз. Аны кисеп алабыз һәм аңа беркетү өчен төрле төстәге йөрәкләр ясыйбыз. Киселгән йөрәкләрне агачкаябыштырып чыгабыз.

Агачның төбе янындагы урынга теләкләр язарга мөмкин. Әлеге матур бүләкне ясау өчен 5–10 минут вакыт та җитәчәк. Ә әниләрегезнең моңа ничек сөенәчәген белсәгез!

КҮЗНЕ ЯЛ ИТТЕРӘБЕЗ

Файдалы

Көн буе компьютер каршында эшләүчеләр һәм телефоннарын кулларыннан төшермәүчеләргә күзне ял иттерү буенча түбәндәге күнегүләр файдага булыр.

✓ Сездән 20 метр чамасы ераклыктагы берәр әйбергә 20 секунд буе текәлеп карап торыгыз.

✓ Күзләрегезне йомыгыз һәм башта сәгать теле уңаена 4 тапкыр, аннары сәгать теле йөрешенә каршы 4 тапкыр әйләндерегез.

✓ Күзләрегезне йомган килеш аска һәм өскә карагандай итегез.

✓ 30 секунд чамасы күзегезне еш-еш ачып һәм йомып алыгыз.

ИР-АТ ӨЧЕН АНА – БЕРЕНЧЕ УРЫНДА

Бервакыт сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.) янына берәү килеп: «Әниемә нинди хөрмәт күрсәтсәм, аның ризалыгына ирешермен, аның алдында булган бурычымны үтәрмен икән?» – дип сораган. Пәйгамбәребез (с.г.в.) җавап итеп: «Әгәр әниеңне кулыңа күтәргән килеш Мәдинәдән Мәккәгә барып, хаҗ гыйбадәте үтәсәң дә, бу әниеңнең сине тапкандагы бер тулгагына да тормый», – дигән. Адәм баласының анасына карата мәрхәмәтле һәм мәхәббәтле булырга тиеш икәнлеген искәрткән сүзләр бу.

Ана хакы һәм ана кадере турында «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН белән сөйләштек.

:: Хәзрәт, Коръәни Кәримдә аналар турында ни диелә?

– Бисмилләһир-рахманир-рахим. Раббыбыз Аллаһ ата-ана турында бергә әйтә. Иң зур гөнаһлар турында әйткәндә телгә ала ул аларны. Ата-аналарга хөрмәт күрсәтмәү иң олы гөнаһлардан санала. Берәү Мөхәммәд (с.г.в.) янына килгән дә: «Йә Рәсүлуллаһ, бу дөньяда мин кемгә иң зур хөрмәт һәм ихтирам күрсәтим? Иң зур мәхәббәт күрсәтим?» – дип сораган. Моңа пәйгамбәр (с.г.в.): «Әниеңә», – дигән. «Аннан соң кемгә?» – дигән сорауга янә «әниеңә» дигән җавап биргән. Өченче тапкырында да пәйгамбәребез кабат шул сүзен әйткән. Дүртенче тапкыр сорагач кына: «Әтиеңә», – дигән җавап ишеткән ул. Ягъни әниләрнең дәрәҗәсе шулкадәр югары.

«Җәннәт – аналарның аяк астында» дигән сүзләрне еш ишетәбез. Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдис-шәрифләрендә болай дигән: «Әни ул – мәдрәсә», ягъни тәрбия бирүче. Ана – батырларны, галимнәрне һәм тәкъва кешеләрне тәрбияләүче. Безне чын тормыш белән таныштыручылар – куркәм холыклы, дини, сабыр, дога кылучы әниләребез. Әлбәттә, баланы карау, аны ашату, киендерү, матди ягыннан хезмәт кылу – барысы да ир өстендә, чөнки ул – гаилә башлыгы. Ул гаиләсен тәэмин итәргә тиеш.

:: Ә ир-ат өчен кем өстенрәк: әнисеме яисә хатынымы?

– Ир-ат өчен иң беренче урында – әнисе, аннан хатыны. Хатын-кызлар өчен киресенчә: башта – ире, аннан әнисе.

:: Хәзрәт, аналарына карата миһербансыз кешеләр дә бар бит. Ахирәттә аларга нинди җәза каралган?

– Әйе, әниләре бәхил итмәсә, кичермәсә, алар җәннәткә керә алмаячак. Гомумән, болар тәмугта булачак.

:: Аналар алдындагы бурычны утәп бетерерлек түгел, диләр.

– Аналарыбызның әманәте бик зур. Без аларны ашатырга, киендерергә, кайгыртырга тиеш. Әгәр дә бай булып та, тегендә-монда сәдака таратып йөреп тә, үз аналарыбызның акчасы даруга да, коммуналь хезмәтләр өчен түләргә дә җитми икән, димәк, бурычыбызны үтәмибез дигән сүз. Шуңа күрә, җәмәгать, әниләребезне кайгыртыйк, күңелләрен күрик, сәламәтлеге нык булсын дип тырышыйк!

pixabay.com

> Раббыгыз сезгә бары тик Аңа гыйбадәт кылырга һәм ата-аналарыгызга яхшы мөнәсәбәттә булуыгызны боерды. Әгәр дә аларның берсе яисә икесе дә картайса, аларга «уф» дип тә әйтмә. Аларга тавышыңны күтәрмә, олылау белән дәш, кече күңеллелек канатларын җәй. «Раббым, аларга мәрхәмәтле бул, алар мине кече вакыттан тәрбияләделәр», – дип дога кыл.
>
> **(«Исра» сүрәсе, 23–24 нче аятьләр)**

:: Шик юк, ана – бөек зат. Әмма күпчелек әниләр балаларына карата бер дә яхшы мөнәсәбәттә түгел. Алар да бала алдындагы бурычны үтәми дигән сүз бит бу?

– Әйе, мондый күренешләр дә юк түгел. Балигъ булмаган балалар эшләре буенча комиссия белән йөргәндә моның белән еш очрашабыз. Бер гаиләдә булган идек. Әнисе – эчкече, эшләми. Балаларына: «Миңа ризык китерегез», – ди икән. Сабыйлары нишләсен? Базарда теләнеп йөриләр, анасына ризык ташыйлар, акча алып кайталар икән. Аллаһы Тәгалә андый аналардан сакласын иде!

:: Ана рәнҗеше балаларга ни рәвешле төшә?

– Әнинең һәр догасы – яхшысы да, бәддогасы да кабул була. Ачуланган вакытта әнисе баласына нидер әйтсә, Аллаһы Тәгалә аны да ишетер. Шуңа күрә, хөрмәтле әниләр, рәнҗемәгез, үпкәләсәгез дә, әйтмәгез, чөнки Аллаһы Тәгалә барысын да кабул итәр.

Декабрь аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Чәрш	05:31	07:48	13:27	15:15	17:10
2	Пәнҗ	05:32	07:50	13:26	15:15	17:10
3	Җом	05:34	07:51	13:26	15:14	17:09
4	Шим	05:35	07:53	13:25	15:13	17:09
5	Якш	05:36	07:55	13:25	15:12	17:09
6	Дүш	05:37	07:56	13:24	15:12	17:08
7	Сиш	05:38	07:57	13:24	15:11	17:08
8	Чәрш	05:39	07:59	13:23	15:11	17:08
9	Пәнҗ	05:40	08:00	13:23	15:10	17:08
10	Җом	05:41	08:01	13:23	15:10	17:08
11	Шим	05:42	08:02	13:23	15:10	17:08
12	Якш	05:43	08:04	13:23	15:10	17:08
13	Дүш	05:44	08:05	13:23	15:10	17:08
14	Сиш	05:45	08:06	13:23	15:10	17:08
15	Чәрш	05:46	08:07	13:23	15:10	17:08
16	Пәнҗ	05:47	08:07	13:23	15:10	17:08
17	Җом	05:47	08:08	13:23	15:10	17:08
18	Шим	05:48	08:09	13:23	15:10	17:09
19	Якш	05:49	08:10	13:24	15:10	17:09
20	Дүш	05:49	08:10	13:24	15:11	17:09
21	Сиш	05:50	08:11	13:24	15:11	17:10
22	Чәрш	05:50	08:11	13:25	15:12	17:10
23	Пәнҗ	05:51	08:12	13:26	15:12	17:11
24	Җом	05:51	08:12	13:26	15:13	17:12
25	Шим	05:52	08:12	13:27	15:14	17:12
26	Якш	05:52	08:13	13:28	15:15	17:13
27	Дүш	05:52	08:13	13:28	15:15	17:14
28	Сиш	05:52	08:13	13:29	15:16	17:15
29	Чәрш	05:52	08:13	13:30	15:17	17:15
30	Пәнҗ	05:53	08:13	13:31	15:18	17:16
31	Җом	05:53	08:13	13:32	15:19	17:17

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Гыйбрәт ал!

Аллаһның барлыгын онытма

Югары уку йортына керергә китәр алдыннан, урта мәктәпне тәмамлаган бер яшь егет хәзрәт янына сугылып чыгарга була.
– Укыгач, кем буласың инде, энем? – дип сораган хәзрәт.
– Юрист булам.
– Аннары?
– Судья я прокурор булып эшкә урнашырмын.
– Ә аннары?
– Аннары өйләнермен, матур гаилә корып, балалар үстерермен.
– Ә аннан соң?
– Пенсиягә чыгармын, оныкларны карашырмын.
– Ә аннары?
– Хәзрәт, үлемнән качып калып булмастыр инде ул…
– Менә шуның өчен, энем, тормышыңның кайсы гына мизгелендә дә Аллаһны онытма, Аллаһ каршында йөзең кызарырлык эш-гамәлләр кылма, мәңгелек урыныңның рәхәттә булсынга максат куй, шуңа омтыл.

(«Локман Хәким нәсыйхәтләре» китабыннан)

Бу – кызык!

Изге китапларыбыз түбәндәге пәйгамбәрләргә индерелгән:
- Муса пәйгамбәргә – Тәүрат (Тора);
- Даут пәйгамбәргә – Зәбур (Псалтырь);
- Гайсә пәйгамбәргә – Инҗил (Евангелие);
- Мөхәммәд пәйгамбәргә – Коръән.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ДИЛӘ НИГЪМӘТУЛЛИНА: «МИН ҮЗЕМНЕ КӨЧЛЕ КЕШЕЛӘР РӘТЕНӘ КЕРТӘМ»

Барыбызга да таныш булган җырчы Дилә Нигъмәтуллина диетолог һәм нутрициолог Дилә Бариева булырга әзерләнә. Тормышындагы үзгәрешләр моның белән генә тәмамланмас, билгеле. Без исә бер урында таптанырга яратмаучы, гел үсешкә омтылучы җырчының бүгенге проектлары, гаилә хәлләре, үз сәгатен көтеп ятучы җырлары турында сөйләшеп алдык.

:: Ни хәл?

– Бар да яхшы, Аллага шөкер! Әле монда туйдан тыш та башка эшләр гөрли. Күптәнге хыялымны тормышка ашырдым – дөрес туклану буенча шәхси курсымны булдырдым. Университетта укыйм. Алла боерса, ике елдан диетолог-нутрициолог дипломын алачакмын.

Туй шушы эшләр арасында бераз югалды, дияргә дә була. Гомумән, без аны болай ук зурлап үткәрәсе түгел идек. Мөнәсәбәтләребезне законлы төстә беркетәсе идек тә, шуның белән шул. Ә әзерләнә башлагач, ниндидер дулкынлану хисләре барлыкка килде. Барысы да балдактан башланды. Иремнең, балдаклар бармы соң безнең, алырга кирәктер инде аны, дигән сүзеннән. Аннан ул костюм кияргә карар кылды. Илсур шулай матур киенгәч, минем дә туй күлмәгеннән барасым килде. Аннан фотограф, чәчәк бәйләме кирәк булып чыкты... Боларның барысын да эзләгәндә, дулкынлану хисләреннән башка булмады, билгеле. Шулай итеп, тыйнак кына узарга тиешле бәйрәм үзе бер вакыйгага әйләнде дә куйды.

:: Туй күлмәге киеп, рәсми рәвештә ир белән хатын булгач, гаиләгездә үзгәрешләр сизелдеме?

– Үзгәрде дип әйтә алмыйм. Сүз арасында: «Булды, хәзер син – минем хатын, мин әйткәнне эшлисең», – дип, шаярышып алабыз инде. Үзгәрешләр күбрәк документта күренә. Иремнең фамилиясен алдым. Хәзер мин – Дилә Бариева. Яңа һөнәр үзләштергәч тә, шушы фамилияне алырга исәплим. Дилә Нигъмәтуллина да юкка чыкмаячак, билгеле. Ул сәхнәдә яшәячәк.

:: Үз мисалыгыздан чыгып әйтегез әле: шәхси тормыш, янында нинди ир булу башка өлкәләргә тәэсир итәме?

– Миңа калса, барысы да хатын-кызның үзеннән тора. Гаиләдә үзен ничек итеп күрсәтә, нинди позициягә куя, ире дә аңа шундый мөнәсәбәттә булачак. Нинди генә өлкәне алсак та, хатын-кызны ире хөрмәт итә икән, аның эше дә уңышлы барачак. Әгәр ул хатын-кыз үзен мыскылларга, кимсетергә рөхсәт итә икән, аның эше, карьерасы да рәтле булмаячак.



Шәхси үсештә тагын нәрсә йогынты ясый? Әлбәттә, күңел тынычлыгы. Гаиләдә үзен яхшы хис итә икән, хатын-кызның яңа үрләр яуларга көче булачак. Ир-ат белән хатын-кыз берсен берсе хөрмәт итәргә тиеш. Мисал өчен, мин ирем белән киңәшләшмичә бернигә дә алынмыйм. Шушы ук укуымны гына алыйк. Диетолог-нутрициолог һөнәрен үзләштерер өчен, 300 мең сумга якын акча кирәк булды. Бу акчаны үзем эшләп тапсам да, ничек мин гаилә малын тормыш иптәшем белән сөйләшми генә чыгарырга тиеш ди? Мондый житди мәсьәләләрдә генә түгел, вак кына карарларны да сөйләшеп кабул итәргә кирәк. Шул очракта гына гаиләдә хөрмәт булачак. Ә хөрмәт ул – гаиләнең умырка баганасы. Хатын-кызның уңышы да шуңа барып тоташа.

Блиц-сораштыру

– Кызыгызга көн дә иртән ни дип әйтәсез?
– Жимешем, алтыным, минем «кудряшкам», чыпчыгым, алма бөртегем. Бөтен булган матур сүзләрне әйтеп бетерәм бугай.
– Үзегезне популяр дип уйлыйсызмы?
Авылда да бакчаларга алмаш булырга тиеш. Аның өчен фанат җитәкче кирәк. Андый җитәкче бар, методикаларын белә, сабыйларның сәләтен ачарга булыша икән, нишләп хезмәтен файдаланмаска? Алар балаларны иртәрәк яшьтән дә ала әле. Бездә хосусый балалар бакчасы биш ел эшли инде. Мәҗбүри түгел, ирекле оештырылган әйбер. Әти-әниләр канәгать, дәгъвалар ишеткән юк. Бәясен төгәл әйтә алмыйм. Анда акчасы булган кеше генә бирә дип әйтмәс иде. Әти-әнине алдап булмый бит аны. Әгәр бәя кыйммәт яки белем һәм тәрбия бирү сыйфатсыз икән, ул анда баласын мәңге бирми. Лицензиясе булмаса, баланы якын китерергә дә ярамый. Бала язмышы, бала сәламәтлеге бит ул. Матди-техник ягы да, тәрбиячеләр әзерлеге дә – барысы да таләпләргә җавап бирергә тиеш. Бу бит – баланың иминлеге. Чит илләрдә күпчелек бакчалар хосусый. Бу – нормаль күренеш.

Юрий ПРОХОРОВ, РФ Халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре берлегенең Татарстан оешмасы җитәкчесе:

Лицензиясез эшләргә ярамый, андыйлар булса, ябарга кирәк. Тиешле документы булмаган мәгариф оешмалары арту – «соры базар» үсә дигән сүз. Лицензиясе булса, хосусый бакчаларга дәүләт ярдәме дә бирелә. Бакчалар законлы рәвештә эшләргә тиеш. Ихтыяҗ булганда, эшләсеннәр.

Наилә Ризванова хосусый бакчада тәрбияче булып эшләгән, хәзерге вакытта декрет ялында.

– Безнең бакча күпкатлы йортның беренче катында урнашкан иде. Бар яктан да тәртип иде. Тик хосусый бакчада әти-әниләр бар нәрсәгә бәйләнә. Без акча түлибез, диләр. Кич килгәч, баласының борыны юеш икәнен күрсәләр, тизрәк тавыш куптара башлыйлар. Без һәр дәрестән соң әти-әниләргә балаларның фото, видеоларны җибәрә идек. Кагыйдәләр шундый. Әгәр фотода бала еласа, йөзен чытып төшсә, кәефе булмаса, әти-әни сиңа рәхмәт әйтмәячәк. Төркемдә иң күп дигәндә – 8 бала. Дәүләт бакчаларындагы кебек 25 бала түгел бит. Шуның кадәр булса, саташып бетәрсең. Кечкенә балаларны «памперс»та килеш китерәләр. Кулда күтәреп йөртә идем. Әти-әниләренә ияләшкән бит алар. Үз кыенлыклары бар инде. Беренче генә баласы булган әти-әниләр «бакчага җайлашу вакыты» дигәнне бөтенләй аңламый. Акча түләгәч, бала авырмаска тиеш дип уйлыйлар. Хет шунда 50 мең сум түләсәләр дә, маңка агу бетми инде ул. Хосусый бакчада күзәтү камералары булу да бик әйбәт. Балалар иминлеге мөһим, – ди Наилә Ризванова.

Сәрия МИФТАХОВА

ТАБИБНЫ ДА, БАКЧАЧЫНЫ ДА КОТКАРА

«КАЗАНОРГСИНТЕЗ» ОЕШМАСЫ 2 МИЛЛИОН СУМЛЫК ДӘРӘҖӘЛЕ ПРЕМИЯГӘ ЛАЕК БУЛГАН

«Кызыл зона»да эшләүче табибларны мәкерле вирустан саклаучы пластмасс битлек, машина фаралары, теплица... «Казаноргсинтез» оешмасында поликарбонаттан җитештерелгән продукциянең кайберләре генә әле бу. Бүген «Казаноргсинтез» Россиядә полимерларның әлеге төрен җитештергән бердәнбер оешма санала. Җитештерү генә түгел, биредә аны табигатькә зыян китермәслек итеп эшли дә беләләр.

Татар-информ / Владимир Васильев

Кечкенә дә төш кенә

Берничә көн элек «Казаноргсинтез» әлеге уникаль эшчәнлеге өчен фән һәм техника тармагындагы дәрәҗәле илкүләм премиягә лаек булды. Поликарбонатларны экологик яктан чиста ысул белән җитештергән өчен оешмага 2 миллион сум акча биреләчәк. Ил күләмендә танылу алган поликарбонатлар җитештерү эшенең асылы белән «ВТ» хәбәрчесе дә танышып кайтты.

Заводларга хас шау-шулы зур бинага атлыйбыз. Биредә әзер продукция зурзур капчык-капларга тутырыла, яхшылап ябыла да саклауга озатыла. Поликарбонат зурлыгы буенча борчакны хәтерләткән үтә күренмәле вак шарчыклардан гыйбарәт. Иженче катта басып торган ират биек автомат җиһаз авызына зур-зур капчыкларны кертеп тора. Автомат машина анда вак поликарбонат кисәкчекләрен тутырып бетергәч, үзйөрешле тасма аны бер рәткә илтеп тезә бара. Соңрак махсус машина капчыкларны саклауга озата.

«Казаноргсинтез» оешмасындагы поликарбонатлар заводының баш инженеры Айдар Вәлитов сүзләренә караганда, поликарбонат, кечкенә булса да, төш кенә икән. «Ул җитештерүдә гранула рәвешендә кулланылган үтә күренмәле, каты полимер пластиктан гыйбарәт. Поликарбонат нык, җиңел, салкынга да чыдам, озак хезмәт итәргә сәләтле», – ди белгеч. Шушы сыйфатлары аркасында бүген ул авыл хуҗалыгы, төзелеш тармакларында, теплицалар ясаганда да кулланыла. Хәтта «кызыл зона»да эшләгән табибларны мәкерле вирустан саклаучы пластик битлекләр дә шушы поликарбонаттан ясала икән. «Поликарбонат пыялага да бик яхшы алмаш булып тора. Ул аның белән чагыштырганда 250 тапкыр ныграк, 2,5 тапкыр җиңелрәк», – ди Айдар Вәлитов. Көндәлек тормышта кулыбыздан төшмәгән кесә телефоны, планшет, ноутбук кебек гаджетлар, көнкүреш техникасы өчен дә без поликарбонатка рәхмәтле булырга тиеш.

Үзе кирәкле, үзе чиста

«Казаноргсинтез» оешмасы поликарбонатлар җитештерүгә 2008 елда кереште. Җитештергән продукция күләмен арттыру өчен, өч ел элек биредә яңарту эшләре башланды. Хәзерге вакытта заводта 415 кеше хезмәт куя. Татарстандагы поликарбонатлар заводы бүген Россия һәм Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләре территориясендә әлеге төр продукцияне җитештерүче бердәнбер завод санала. Биредә җитештерелгән поликарбонат хәтта Европа илләренә дә озатыла.

Оешма белгечләре бу очракта ике куянның койрыгын берьюлы тоткан. Бер яктан, «Казаноргсинтез» бүген дөнья күләмендә ихтыяҗ зур булган һәм башка илләр өчен шактый яңалык саналган үзгә продукт җитештерүгә күчкән. Икенче яктан, аны тирәлеккә, табигатькә зыян салмаслык итеп эшләү юлын тапканнар.

– Бүген дөнья күләмендә поликарбонатлар җитештерүнең ике ысулы билгеле. Аның берсен кулланганда фосфоген дигән зарарлы матдә бүленеп чыга. Ул кешеләр өчен дә, әйләнә-тирә өчен дә зур куркыныч тудыра. Өстәвенә аны кулланганда агып җыела торган су да күп чыга. Бездәге җитештерү барышында фосфоген бүленеп чыкмый. Һаваны углекислый газ да пычратмый. Ул бездә, киресенчә, чимал буларак кулланыла, – ди «Казаноргсинтез»ның поликарбонатлар заводы директоры Андрей Пресняков.

Баштарак поликарбонат заводы елына 65 мең тонна продукция җитештерәчәк дип планлаштырылган булса, хәзер бу күрсәткечне 90 мең тоннага җиткергәннәр. Киләсе елга исә 100 мең тонна поликарбонат җитештерергә планлаштыралар. Моннан тыш, яңарту эшләре барышында заводта электр куллануны, һавага бүленеп чыккан калдыклар күләмен дә киметү күздә тотыла.

Уртак хезмәт җимеше



Илкүләм премиягә ия булу исә бу максатларны чынга ашырырга, тагын да нәтиҗәлерәк эшләргә зур этәргеч бирәчәк, дип ышана завод белгечләре. «Бу хәбәрне ишеткәч, бик шатландык. Көтелмәгән хәл булды», – ди Андрей Пресняков. Соңгы арада заводта поликарбонатлар җитештерү, ассортиментны арттыру, аларның куллану даирәсен киңәйтү юнәлешендә бик зур фәннитехник эш алып барылган. Җитештерүне экологик яктан чиста башкару юлларын да эзләгәннәр. Илкүләм премияне алу өчен тәкъдим ителгән эш нигезендә дә әнә шуның нәтиҗәләре урын алган.

– Әлеге хезмәткә өлеш керткән авторларның гына түгел, шушы эшнең чишмә башында торган «ТАИФ» акционерлык оешмасы җитәкчелегенең дә җиңүе бу. «Казаноргсинтез» мәйданчыгында дөнья күләмендә киң таралу тәҗрибәсе булмаган нәкъ менә шушы җитештерү төрен йөрәксенеп башлап җибәрүләре игътибарга лаек. Бу җиңүгә заводта хезмәт куючы барлык эшчеләрнең дә өлеше керде, – ди оешманың баш инженер урынбасары Дамир Сафин *(рәсемдә)*.

«Казаноргсинтез» оешмасы 2022 елны яңа максат, үрләргә илһамландырган әнә шундый уртак, зур җиңү белән каршылый.

> Хәзерге вакытта поликарбонатлар куллану базары иң тиз үсеш ала торган юнәлешләрнең берсе санала. Якын киләчәктә дөнья күләмендә аларны куллану дәрәҗәсе елына 6 миллион тоннага җитәр дип фаразлана. Узган ел Россиядә генә дә елына 100 мең тонна поликарбонат файдаланылган.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БЕРТУГАН ТАБИБ МӨХӘММӘТҖАНОВЛАР:

«ӨЙЛӘНЕРГӘ ТАТАР КЫЗЛАРЫ ЭЗЛИБЕЗ»

Питрәчтә туып-үскән Илсур, Илнар, Илнур Мөхәммәтҗановлар кәләш эзли. Өчесе дә – табиб, Мәскәүдә эшлиләр, ә иң кызыгы: алар – игезәк туганнар. Бәхет эзләп, «Беренче канал»дагы «Давай поженимся!» тапшыруына барганнар. Булачак кәләшләргә таләпләре дә зурдан. «ВТ» хәбәрчесе 27 яшьлек игезәк табибларның әти-әнисен эзләп тапты.

Мөхәммәтҗановлар әйтүенчә, аларга башын югалткан кызлар кирәкми. Кәләш күпбалалы гаиләдән булса яхшырак. Озын толымлы, сау-сәламәт, кеше белән аралаша белгән, бала табарга әзер туташлар белән кавышырга өметләнәләр. «Тәкъдим иткәч, кызык эзләп бардык инде тапшыруга. Әмма андагы кызлар, дөресен әйткәндә, җанга якын булмады. Безгә татар кызлары кирәк. Безнең кебек игезәк булсалар, тагын да яхшырак», – ди Илсур Мөхәммәтҗанов.

Егетләрнең өчесе дә Казан дәүләт медицина университетын тәмамлаган. Илсур белән Илнур – педиатрия, Илнар исә дәвалау факультетында белем алган. Башта Питрәч районында һәм Казанда эшләп алганнар, аннары, бәхет эзләп, Мәскәүгә чыгып киткәннәр. Өчесе бергә яшиләр. Бертуган Мөхәммәтҗановларның табиб һөнәрен сайлавы гаҗәп түгел. Чөнки әтиләре Рәис тә озак еллар кеше сәламәтлеген кайгырта: Питрәч районы хастаханәсендә акушер-гинеколог булып эшли. Меңләгән әнигә һәм бәбигә ярдәм иткән. «Тумышым белән Буа районыннан булсам да, укуны тәмамлагач, юллама белән Питрәчкә җибәрделәр. Шунда төпләнеп калдым инде. Үзем дә медицина өлкәсендә эшләгәч, балаларның табиб булуын теләмәгән идем. Алар бу юлны үзләре сайлады», – ди ул.

Мөхәммәтҗановларның олы уллары да бар. Әйеәйе, Илшат та табиб булып эшли! Өйләнгән, хатыны Алсу белән 2 бала үстерәләр. Казанда яшиләр. Киленнәре дә – үзләре кебек табиб.

– Илшат улым өч яшендә бәби сорый башлады. Миңа бер кыз, ике малай алып кайтыгыз, ди бу. Мин аңа кат-кат аңлатып та карыйм, тик Илшатның үз сүзе: аңа өчәү кирәк, – ди 4 табиб тәрбияләп үстергән Светлана ханым. – Авырга узгач, карынымда өч бала бардыр дип уйламадым да. Дөрес, ирем ягыннан да, бездә дә игезәкләр күп. Әмма берьюлы өчне табуны көтмәгән идем. Бакчада эшләп, халат кына киеп йөрдем. Балалар бакчасында тәрбияче булып эшләп йөрим. Төрле чаралар уздырырга кирәк. Корсагым, кем әйтмешли, ай үсәсен көн үсә башлады. Рәис тә шаккатa. Инде өч айда Илшатны табарга барганда кигән күлмәгем генә ярый башлады. Берәр кимчелек юк микән, дип ирем мине УЗИга җибәрде. Ә андагы табиб карый торгач, бөтенләй сүзсез калды. Икәү монда, ди. Соңгы айларда халат кына киеп йөрдем. Бакчада эш бар, хайваннар тотабыз. Бик арый идем. Ирем кабат УЗИга алып барды. Андагы табиб, ике малай күрәм һәм тагын берне, ди. Мин бик тә кыз көткән идем. Малай күрсә дә, Рәис абыең алдан кисәтеп куйгач, дәшми калган икән ул. Малайларны 36 атнада ярып алдылар.

Өч малайны үстерү җиңел булмый. Баштарак бигрәк тә. Өйдә 4 яшьлек Илшат та бар бит әле. Җитмәсә, Светлана ханымның үз сәламәтлегенә дә какшап китә. Кайбер төннәрен йоклый да алмый. Берсен имезә башласа, икесе кычкырып еларга тотына. Әмма бирешми. Баһадирларын үстерер өчен үзендә көч таба.

– Бер ел бик авыр булды. Ул чакта, мине кызганып, эшемнән хезмәттәшләрем көндез килеп ярдәм итәләр иде. Шулай итеп, әкренләп улларым үсеп китте. Шук булсалар да, бер дә борчу китермәделәр. Баларны аякка бастыру җиңел булмады. Әтиләре агач эшенә өйрәтеп үстерде. Мәктәптә укыганда ике катлы агач караватлар ясап саталар иде инде. Мал да асрадык, бакча тутырып яшелчә үстердек. Үз ризыгың белән яшәү җиңеләйтте, – ди Светлана ханым.

Егетләрнең үзләре белән сөйләшә алдык. Аларның эшләре тыгыз. Илнур ковид бригадасында терапевт булып эшли икән. Илсур белән Илнар – педиатрлар. Берсе – шәхси клиникада, икенчесе дәүләтнекендә хезмәт куя.

– Без аерым тора алмыйбыз. Өчәү бергә булганда күңел тыныч. Үз юнәлешләребез буенча китап та чыгардык. Халык белән социаль челтәрләрдә бик актив аралашабыз. Яшь әти-әниләр күп кенә проблемалар алдында югалып кала. Әнә шундыйларга киңәшләр бирәбез. Мәскәүдә яшәвебез вакытлыча гына. Казанда өчебезнең дә эш урыны булса, китмәс тә идек. Киләчәктә туган якка кайтып, анда өчебезгә дә эш табып, бер урамда өч йорт салып яшисебез килә, – ди Илсур.

Әниләре дә улларының бер-берсенә бәйлелеге нык булуын әйтә.

– Алар гел бергә. Илнурга дип йорт салып куйдык инде. Калган балаларыма да җир бар. Әкренләп аларның да үз куышы булыр. Иң мөһиме – исән-сау булсыннар, – ди Светлана Мөхәммәтҗанова.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Язып кына карыйм

БАШСЫЗ КЕШЕ ЯЗМАЛАРЫ

Бу язмаларны мин башта «Башсыз кеше язмалары» дип атарга теләгән идем. Бөтен кеше дә шулай кичерә микән аны, миндә генә шундый булдымы икән – ковид эләктергәч, баш юньләп эшләми башлый. Тормышны бөтен нечкәлекләре белән кабул итәлмисең, үзеңне танк эчендә, противогаз киеп йөргән кебек тоясың. Сүзләр акрын барып җитә, саңгырау кеше кебек ишетми торасың, ишеткәч, мәгънәләре аңлашылып бетми, күзләр күрү җитезлеген югалта...

Баш та бик эшләп бетерми бугай, моңа кадәр элеп кенә ала торган нәрсәләрне дә авыр кабул итәсең... Авырганда кешенең каны куера дип әйтәләр, бәлки шул сәбәпчедер инде моңа, кан куергач, әкрен йөридер, син алырга тиешле мәгълүматны үз вакытында китереп җиткерәлмидер. Һәрхәлдә, мин бу күренешне шулайрак кабул иттем.

Менә шул халәттә нәрсәдер язу җиңел түгел. Мондый чакта үз уйларыңның дөреслегенә тулысынча ышанып булмый. Башыңа килгән фикерләр дә башта бик мавыктыргыч булып тоела да бераздан төссезләнеп кала, мәгънәсен югалта, күп очракта үзләре дә эзсез югала. Хәтер югалту да, бәлки, шулайрак башланадыр. Кайчагында үзеңнең туу датасын да тиз генә әйтәлми торасың.

Минем хәл бик авыр кебек түгел иде. Шуңа хастаханәдә яткандa ерып чыгармын дип китаплар алдым, аудиокитаплар, электрон вариантлары, кинофильмнар... Сызланудан интегеп ятмасаң, алар яхшы юлдаш инде. Вакытыңны кызыклы һәм файдалы уздырырга ярдәм итәләр, яза торган әсәрләргә мәгълүмат туплау өчен дә кирәк, әдәбият дөньясы белән танышып бару өчен дә, гомумән, үзен формада тоту өчен дә язучыга китап кирәк.

Ләкин бер китапны да тулысынча укып булмады. Йоклыйсың да китәсең. Укыган өлеше дә аңыңа үтеп керәлми. Онытыла. Хәтта халык акча түли-түли егылып ятып карый торган фильмнар да кызык түгел. Мин аларның берсен дә ун-унбиш минуттан артык карый алмадым. Кызык түгел. Йоклата. Кайбер китапларны укыганда йоклап китәсез икән, авторны хурларга ашыкмагыз, бу әле китап начар дигән сүз түгел, бу әле сезнең чирле икәнегезне искәртергә дә мөмкин.

Моны сизеп алгач, курку барлыкка килде. Әгәр гомерлеккә шулай «торможенный» булып калсам? Ә бу бик мөмкин иде, чөнки әлеге халәт берничек тә чигенергә уйламый. Мин һәрвакыт шундый хәлдә. Танк эчендә, противогаз киеп йөргән кебек. Бокс перчатканары киеп, симечке ашаган шикелле. Мондый хәлдә тормышны кабул итү дә бераз үзгәрә бугай.

Язу, беренчедән, баш миен күнектерү мөмкинлеге бирә, уйларыңны аз гына булса да йөгерек итә. Икенчедән, шушы халәттә тормышны кабул итү үзе дә кызыктыр сыман тоелды. Өченчедән... Беркемнең дә ковид эченнән күзәтүләр алып барганы юк әле... Тагын мин беренче булачакмын... Язучының башын нәкъ менә шул беренче булу теләге ашый торгандыр да инде.

Ләкин соңыннан карап чыккач, исемен үзгәрттем. «Башсыз кеше» дип атау үземне кимсетү кебегрәк тоелды. Болай да бик алга алып торучы юк, үзем дә мөмкинлек бирмим әле, дип уйладым. Үземнән бигрәк, Ходайны кимсетү кебек тоелды. Чөнки мин елына берничә роман яки повесть язам. Боларны Аллаһы Тәгалә бирәдер дип уйлыйм. Тәҗрибә зур, дөрес уйлыймдыр – Ходай бирмәсә, бик әллә кая китеп булмый ул. Үземне башсыз дип атасам, ни теләсәм, шуны үзе эшләп бирә торган Ходайга да тел тидергән кебек булыр дип курыктым. Ә авыр хәлгә калганда, бил авыртканда һәм, гомумән, чирләгәндә Ходай Тәгаләне искә төшереп, «Алла, билем...» дип булса да куярга кирәк... Боларны аңларлык булгач, бөтенләй үк башсыз кеше түгел бит инде.

Шуңа күрә, бу язмаларны мин «Язып кына карыйм...» дип үзгәртергә булдым. Болар – шундый рәхәт күзәтүләр, кайсы ягы беләндер безнең кайбер язучыларның романнарын хәтерләтә: ничәнче битеннән башлап укысаң да, бернәрсәсе дә үзгәрми. Уйфикерләрем нәкъ сезнеке кебек әйбәт минем, сүзләре генә бераз буталып киткән. Барысына да ковид гаепледер...

Дәвамы киләсе саннарда >

ВИНЕРА ГАНИЕВА:
«КЫШ – МИНЕМ ӨЧЕН ИҢ ЯМАНСУ ФАСЫЛ...»

Уңыш артында ни ята? Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Винера ГАНИЕВАның гомер йомгагын сүткәндә, бу сорауга җавап табылды да кебек. Эзләнү, үзеңне төрле өлкәләрдә сынап карау, хыяллану, шул хыялларны тормышка ашыру икән уңышның сәбәпләре. Без танылган җырчының үткәне һәм бүгенгесе, эстрада хәлләре, табышлар һәм югалтулар турында сөйләштек.

:: Консерваторияне тәмамлап, Опера һәм балет театрына аяк баскан вакытларны искә төшерик әле. Ул вакытта яшь артистларга нинди таләпләр куела иде, хәзер нинди? Гомумән, бүген җырчыга катгый таләпләр куеламы?

– Консерваториянең бишенче курсында укыганда мине стажерлар труппасына кабул иттеләр. Ул 1982 ел иде. Опера классында театрның баш режиссеры Нияз Курамшевич Даутов укытты. Күрәсең, миндә сәләт, тавыш мөмкинлекләрен күргәндер, театрга чакырды.

Консерваторияне тәмамлаганда чыгарылыш курсы студентлары арасында вакансияләр ярминкәсе була. Анда төрле театрларның директорлары, дирижерлары, режиссерлары килә. Студентлар алар алдында үз осталыкларын күрсәтә. Әлеге чарада мин Россининың «Севильский цирюльник» операсыннан Розина каватинасын башкардым. Чыгышым тәмамлангач, оркестр музыкантлары смычоклары белән пюпитрга кагылып, соклануларын белдерделәр. Казан дәүләт Опера һәм балет театры дирижеры Владимир Васильев шул чыгыштан соң опера театрына чакырды. Һәм мин 1983 елдан театрның төп солисты булып кабул ителдем, хәзерге көнгә кадәр шунда эшлим. Театрның яшь җырчыларына тәҗрибәмне җиткерәм, гомумән, нәрсә беләм – шуның белән уртаклашам. Үзем дә кечкенә генә булса да партияләрне чыгып җырлыйм. Ул да зур шатлык хисләре бүләк итә. Сәхнә – миңа көч бирә торган урын ул. Киләсе елга сәхнәгә килүемә 40 ел була.

Ул вакытта нинди таләпләр дигәндә, нинди генә партия бирелсә дә, кечкенәме ул, зурмы – бөтенләй җаваплылык белән карарга, өйрәнергә, хәрәкәттә булырга, эзләнергә, дәресләр алырга кирәк. Мин шулай эшләдем. Параллель рәвештә радиога да җырлар яздырырга йөрдем. Хәзерге дәрәҗә – шул хезмәтнең нәтиҗәсе. Актерлык һөнәре тынгысызлыкны ярата. Бер партияне өйрәнеп бетерү белән, икенчесенә алына идем, үземне үстерергә, хезмәт белән яшәргә тырыштым. Бу исә – үзеңне, тавышыңны тонуста тотарга кирәк дигән сүз. Төп рольне башкаручы авырып китә икән, көнендә шалтыратып, кич белән чыгыш ясарга кирәк була, дип чакырганнары да булды.

Миңа калса, җырчыга элек нинди таләпләр булган, хәзер дә шулай. Чын профессионал, тирән белемле булу кирәк. Тавыш кына җитми, актерлык сәләтен дә үстерергә кирәк.

:: Опера театры артисты булу – үзеңне формада тоту дигән сүз бит әле ул. Серләре белән бүлешегез әле. Әйтик, концерт алдыннан нәрсәләрдән тыелырга кирәк?

«Татар-информ»

– Опера жанры – иң югары баскычтагы сәнгать төре. Ул бик зур хезмәт таләп итә. Монда көн саен шөгыльләнмичә, вокаль күнегүләр ясамыйча булмый. Җырчыга иң кадерлесе – тавышы. Аннан соң хәтер. Ул бик зур арияләр белән эш итә, боларның барысын да хәтердә калдырырга кирәк бит.

Чыннан да, опера җырчысы тормышында чикләүләр бик күп. Әйтик, билгеле бер ризыкларны – көнбагыш, чикләвек, туңдырма ашарга ярамый. Газлы су, баллы су да эчәргә ярамый. Һәркемнең организмы үзенчәлекле, шуңа һәркем үзенә карап нәрсәләрнедер чикли. Мин, мәсәлән, банан, алма, әфлисун ашамый идем. Тавыш яңгырасын өчен концертка кадәр 3–4 сәгать алдан ит ашарга ярый.

:: Винера Ганиева, Айдар Фәйзрахманов, Хәйдәр Бигичев чорында профессионаллар популяр булса, хәзер халык күбрәк үзешчәннәргә тартыла кебек... Ни өчен шулай килеп чыкты икән?

– Хәзер үзешчән җырчыларның кайберләре профессиональ җырчылардан да өстен тора. Минем шуңа игътибар иткәнем бар. Безнең халык талантлы, шуңа үзешчән сәнгатьнең үсүе бер дә гаҗәп түгел. Бу күренешне хуплыйм, аларның иҗат итәргә дә, яшәргә дә тулы хаклары бар. Мөмкинлекләр заманында яшибез. Теләге булган кеше студиядә җыр яздырганда бөтен кимчелекләрен яшерә ала. Җыр туа, аны шунда ук ротациягә бирәләр. Сәнгатьтә – тулы демократия. Үз сүзеңне әйтәсең килә икән, әйтәсең, җырлыйсы килә икән, җырлыйсың.

Ә шулай да, тамашачы барыбер затлы җырчыны һәвәскәрдән аера белә. Үз йөзең, үзенчәлекле репертуарың, стилең булмаса, тамашачыга кызыгың калмый. Ул бер килә андый концертка, икенче юлы инде борылып та карамаска мөмкин.

> Элек бит худсоветлар бар иде. Җырлар җиз иләктән бөртекләп-бөртекләп кенә узды. Ул вакытта үзешчән сәнгать аерым, профессиональләрне аерым юнәлештә үстерделәр, бер-берсе белән бутамадылар. Хәзер инде барыбыз да бер сәхнәдә, ботка булдык... Артистларның кайсы белемле, кайсы белемсез...

:: Тамашачыны затлы сәнгатькә тарту өчен нәрсәләр эшләргә кирәк икән?

– Тамашачы күңеленә хуш килгән җырчыны сайлый, аны күзәтә, концертларына йөри. Бу очракта төгәл генә берни дә әйтеп булмый. Беләсезме, бер көнлек җырчылар һәрвакыт булган һәм булачак. Ләкин алар вакытлы һәм үзләренең вакытлы булуларын үзләре дә яхшы белә. Ясалма күтәрелеп тарихта калып булмый. Ә инде затлы сәнгатькә чын мәгънәсендә бирелгән кешеләр алар үзгә. Андыйлар музыкаль белем алу юлын сайлый, укый, үзен затлы сәнгатькә багышлый.

:: Сез башлап җибәргән «Йолдызлар фабрикасы» бик күп талантларны ачты, әле дә укучылар әзерләү юнәлешендә эшлисез. Педагоглык эшчәнлегендә иң авыры нәрсә?

– Әйе, Казан мәдәният институтында 25 ел педагог булып хезмәт итәм. Ә «Йолдызлар фабрикасы» проекты белән гастрольләрдә бик күп йөрдек. Студентларга «фабрика»га эләгү бик зур стимул иде. Ул үзем өчен дә ачыш булды. Чөнки монда бер сәхнәдә остаз һәм шәкерт эшли. Мин алып баручы да, режиссер да, сценарий авторы да идем. Чыгыш ясаучының сыйфатларын еш кына шигырь юллар белән әйтеп бирә идек. Бу җәһәттән дустым Рәзинә Сәетгәрәева бик ярдәм итте. Ул һәр шәкерткә багышлап шигырь яза иде. Тамашачы бу алымны бик яратты.

Шәкерт остазның сәхнәдә алып баруын, тамашачы белән элемтә урнаштыруын – барысын да күзәтә, үзенә күрә практик дәрес ала иде. Бу элемтә бик кирәк. Үзем дә – заманында шундый ук мәктәпне узган кеше. Безнең концертларны Гөлшат Зәйнашева, Айрат Арсланов алып барды. 89 нчы татар мәктәбендә укыганда да, безгә атна саен филармония артистлары килә иде. Наҗия Теркулова, Венера Шәрипова безгә затлылык сабагы биргән булган икән.

Педагог булу җиңел түгел. Монда теләк кенә җитми. Тәҗрибә туплаган булуың, методикаң, квалификацияң булу кирәк. Педагог белән укучы арасында

Блиц-сораштыру

– Мөмкинлек булса, тормышта нәрсәне үзгәртер идегез?

– Бернәрсәне дә үзгәртмәс идем. Яшәгән кадәре матур булды, алдагысы да мәгънәле булсын. Артка карап шөкер ит, алга карап фикер йөрт, диләр бит. Минем өчен иң мөһиме – сәламәтлек. Аның өчен үзеңне карарга, ихтыяр көчеңне бер йодрыкка тупларга, дикъкатеңне үзеңә юнәлтергә кирәк. Мин җәяү йөрергә яратам. Яңгыр булса да, кар булса да, бу гадәтемне ташламыйм.

– Хәзерге мизгелдә күңелгә килгән җыр исеме?

– «Гомерләрне үлмәс җыр итик». Һәр кеше тормышта үз эзен калдырырга тиеш. Моның өчен артист булу кирәкми. Кеше булып калырга кирәк. Шул чакта сине үзеңнән соң да сагынып искә алырлар.

– Сезнең фикерегезчә, эстрадада иң уңышлы проект нинди иде?

– Сәнгатьтә проектлар бик күп. Аларның һәрберсенең – үз урыны, үз миссиясе. «Йолдызлык» та, «Яңа татар җыры» да, Әлфия Авзалова исемендәге конкурс та үз миссиясен башкара. Минем «Сандугач» конкурсы да, «Үзгәреш җиле» дә үз миссиясен үти. Алар һәрберсе үз урынында. Сәнгать төрле юнәлештә, төрле жанрларда үсәргә тиеш. Үсештә булган өлкә генә халыкка тәэсир итә ала.

– Тормыш девизыгыз нинди?

– Мин аны, шагыйрь Роберт Миңнуллинның шигыренә таянып, һәр концертта әйтәм. Без бу дөньяга яратыр өчен туганбыз. Туган илебезне, телебезне, туган йортыбызны, әти-әнине, сөйгән ярны яратырга кирәк. Бу девиз һәр кеше йөрәгендәдер, мөгаен. Тормышның мәгънәсе – яратуда.

– Казан ул – ...

– ...туган җирем, горурлыгым. Мине үстергән, тәрбияләгән, белем биргән, хезмәтле иткән Казанны бик яратам. Мин – «Теплоконтроль» янындагы баракта туган бала. Өч бала озын коридорларны тутырып йөгереп йөри идек. Шул коридорда һәр хуҗабикәнең тезелеп киткән керосинкалары хәзер дә күз алдында. Шуннан «хрущевка»га күчтек, аннары тагын да уңайлырак фатирларга күчендек. Хәзер инде 16 ел үз йортыбызда яшим. Бу да һавадан төшкән мал түгел. Тир түккән зур хезмәтнең нәтиҗәсе.

аңлашу булырга тиеш. Укучы белән мөгаллим арасында әлемтә булганда гына, шәхес тәрбияләп була.

:: Сезнең тагын нинди максатыгыз чынга ашмады әле?

– Максатларым барысы да тормышка ашты, иҗатта барысы да барып чыкты. Укучыларымнан бик канәгать, күз тимәсен, барысы да сәхнәдә балкыйлар. Бу да бит – бик зур бәхет. Шәкертләренең иҗади уңышлары – остаз өчен зур дәрәҗә дә, шатлык та.

Мин гаиләдә дә бик бәхетле булдым. Камилем белән 36 ел бергә яшәдек, мин иң бәхетле хатын идем. Ул мине иҗатымда үстерде, канатландырды, илһам бирде. Миң аңа бик рәхмәтле.

:: Академия театры роль тәкъдим итсә, ризалашыр идегезме?

– Камал театрында җиде сезон «Зәңгәр шәл»дә Мәйсәрәне уйнадым. Бу актерлык ягыннан зур тәҗрибә булды. Марсель Сәлимҗановка аның өчен бик зур рәхмәт. Ул «Риголетто»ны карарга килгән иде, спектакльдән соң сәхнә артына үтеп, Камал театрына чакырды. Күп кенә опера артистлары күбрәк җырлауны кайгырта. Сәхнәдә уйнамаска, хәрәкәтләрне чикләргә тырышалар. Ул табигый да, хәрәкәт вакытында дөрес итеп тын алып булмый. Бу исә җырлау сыйфатында чагылырга мөмкин. Мин сәхнәдә онытыла идем. Миңа хәрәкәтләнү дә, җырлау да кирәк иде. Сәхнәдә тиктормас җан булдым. Җыр һәм уйнау бер булырга тиеш. Шул вакытта гына тамашачыга синең образың барып җитә. Образлы фикер йөртү дип атала ул. Җыр сәнгатенә дә кучтә бу сыйфат.

> Җыр бит ул сүзгә көйне чорнап бару гына түгел, һәр сүзнең төмен аңлап, аны җиткерә белү дә кирәк. Җыр ул – хис. Эчтәлек хис аша биргәндә генә ачыла. Мин формаль җырчы була алмадым инде.

:: Сүз уңаеннан, «Инстаграм»да исемегез Винера дип язылган, элек Венера Ганиева дип яза идек. Үзгәрешнең ниндидер сәбәбе бармы?

– Паспортта Винера дип язылган. Минем өчен иң дөресе – паспортта язылганча, ә инде афишаларда Венера дип язалар икән, аңа исем китми.

:: «Инстаграм» сәхифәгездә соңгы пост «Бер ел була инде, бер ел була, Синең мине калдырып киткәнгә...» дигән моңсу шигырь белән бәйле. Югалту ачысы кимеми, дисәләр дә, күңел азрак тынычландымы, Винера апа? Камил абый төшләрегезгә керәме? Әйтелми калган сүзләр бармы?

– «Инстаграм»да актив блогер булмасам да, сәхифәне алып барам. Күптән түгел Гөлнур Галимова, минем хәлемне аңлап, шигырь юлларын җибәрде. Камилнең киткәненә 28 декабрьдә бер ел була... Ел ашын үткәрү турында уйлыйм, шуңа әзерләнәм. Бер ел була, әле төшкә бер дә кергәне юк. Аны сагынмаган, юксынмаган, еламаган көнем юк.

Кыш – минем өчен иң ямансу фасыл. Узган кышта Камилемнән аерылдым. Менә тагын карлар яуды. Элек Камил ишегалларын көри иде, хәзер миңа калды. Рәхмәт шәкертләремә: узган елны машиналарга төялеп килеп җитәләр иде.

Мин бик бәхетле хатын булдым. Чын ирнең нинди булганын белдем, шуны татыдым. Камил абыегызны бик күп кешеләр сагына. Ул ярдәмчел, итагатьле, намуслы кеше иде. Әйтелми калган сүзләр була, алар бетми инде беркайчан да. Яшәү дәверендә сүзләр әйтелеп бетмидер ул.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ТАМГА

(ХИКӘЯ)

< Дәвамы. Башы 4, 12, 19 ноябрь саннарында

Нурихан, кая барып бәрелергә белмичә йөргәндә, ике кызның бакча буенда гәпләшеп утырганын абайлады. Берсе – Шәрифә, икенчесе сары чәчле Сафринә иде. Зимагур Шакирның сабый килеш карт әнкәсенә кайтарып ташлаган үги кызы ул. Озын толым бу шаркылдык белән нинәрсә турында сөйләшә икән? Моңарчы алар бер-берсен өнәмиләр иде бит.

Абзар читенә посып, үсмер «сердәшләр»не күзәтте. Чү, Шәрифә кинәт аркан ауды. Ә Сафринәсе, бот чабып көлә-көлә, аның авызына нидер тутыра. Җәядәге ук кебек бакча башына очты егет. Аны күргәч, сары чәч шыпан-шыпан артка чигенде.

– Ул үзе тилебәрән ашады, үзе! – дип чыркылдады кыз. – Мин өстәдем генә!

Җансыз гәүдәне күтәреп, Фәсыйләләргә чапты Нурихан. Табанын нәрсәдер кисте, нәрсәдер кадалды, ә ул чапты да чапты. Бәхетенә, кендек әбисе – имче Фәсыйлә өйдә иде.

– Яшәүдән бизгән мәллә Билалетдин кызы? – дип әрли-әрли, ул Шәрифәне караватка яткырды. – Син, җегетем, минем идәнемне кан белән таплама. Мә чүпрәк, аягыңны юып бәйлә.

Баскычка чүмәшеп аягын караса, Нуриханның күзе шакмакланды. Табанын зур гына пыяла кисәге ярып кергән иде. Аны тартып алгач, кан сиптерде. Егет, сыңар аякта гына сикергәләп, бәрәңге бакчасына чыкты да ярасына учлап-учлап туфрак сипте. «Туйга кадәр төзәлә», – диләр картлар. Шәрифә генә терелсен иде! Тилебәрән орлыгының агу икәнен үләнче кыз белмәде микәнни?!

Имче Фәсыйлә титаклый-титаклый ишегалдын әйләнгән Нуриханга тәрәзәдән башын тыгып боерды:

– Ата каз сымак чирәмемне таптама, өеңә тай! Билалетдин кызы үлми, монак күзен ачтырдым, – диде.

Егет яралы аягын сөйрәтеп кенә Сафринәләр турыннан узганда, бияләй хәтле авызын ерган чая кыз капкаларына сөялгән иде.

– Нәстә ыржаясың, марҗа чәч! – диде Нурихан, җенләнеп.

– Теге имгәкне күмеп үк кайтышың мәллә, аксак карга? – дип телләште Сафринә.

Нурихан җирдән таш эзләде. Шаркылдыкның ерык авызын ямасаң, бәлки, бүтән сайрамас иде.

– Әй күтәрде дә чапты тегене! Ха-ха-ха.

Ачуы кабарган үсмер, йодрыгын төйнәп, Сафринәгә ыргылды. Кыз качмады, капкага ныграк терәлеп басты.

– Кил, кил, иркәм. – Аның күзеннән дәртле очкыннар чәчри иде. – Кил... Мин синнән ике яшькә олырак. Миңа быел уналты. Синең беләкләрең таза да, матур да, билемнән уратып кочаклачы, иркәм.

Нурихан бу тәкъдимнән югалып калды. Йодрыкка укмашкан бармаклар үзеннән-үзе язылды. Шәрифәнең күлмәк җиңенә кул тидерергә ярамаганда, күр, бу марҗа чәч «кочакла» ди!

– Яле, иркәм, тотып кара, минем йомрыларым нинди зур, нинди тыгыз, – дип, күкрәген калкыткан кызны Нурихан җирәнеп этеп җибәрде:

– Фу, синнән сасы ис килә!

Сафринә үпкәләмәде, коймага эленгән идән чүпрәге белән култык астын сөртә-сөртә:

– Җитлекмәгән икән әле син, аучы малае, – диде. – Тәккә ымсындым сиңа. Ничава, соңрак яратышырбыз. Әбекәй туңкайса, ишекне бикләмәм.

Кызык, Сафринәнең чытлыкланып сөйләшүләре дә, килеш-килбәте дә күрше Орловка авылы марҗаларыныкына охшаган. Наратлык кызлары үзләре әдәпле, үзләре тыйнак. Егетләргә башлап сүз катарга да ояла алар.

Ләкин, үпкәләмәсә дә, чая кыз – кара елан – йөрәккә каты чакты:

– Син, аучы малае, сәлам сыйрак Шәрфә дип саргайма, җәме? Аның сине җене сөйми. Күтәреп чаптың чабуын, иркәм. Мин тилебәрән белән тыгындырдым аны, мин! Нурихан җүнсез аркасында үләсем килә, дигәч, үлсен, мәйтәм. Авыл урамнары сулышка иркенәер.

Нурихан аксый-туксый кителп барды. Күңелсез хәбәр иде бу. Ни өчен Шәрифә аны кыралмый икән? Ни өчен? Нишләгән ул кадәр Нурихан?

...Аучы Миннехан өч көннән әйләнеп кайтты. Киеме ертылган, куллары тырналып беткән иде.

– Кая, су бирегез! – диде ул, тамак төбен гырылдатып.

Изүенә агыза-агыза ярты тустаган су эчкәч, ата, канәгать елмаеп:

– Каптырдым, – диде. – Миннән калмады. Читәндә алар, улым, – диде.

Нурихан урамга атылды. Басу капкасы янында җыелган халык читәнгә атландырган ике симез бүрене тамаша кыла иде:

– Гайрәтле инде Миннехан!

– Ничек авылга кадәр өстерәгән боларны? Көч үзендә, ә!

– Ай-һай, таза бүреләр!

– Катыннар, иртән урманга барабыз!

Шәрифә дә килгән иде. Ул, башын иеп егет янынннан үткәндә, «рәхмәт» дип пышылдады. Нәрсәгә «рәхмәт» ди Озын толым?! Юньсез Нурихан ниндидер билгесез сәбәпләр белән аны үлемгә этәргән ди бит! Үсмер андый ук җебегән түгел иде. Тыкрыкта Шәрифәне куып тотып, беләгеннән кысты:

– Ник тилебәрән орлыгы ашадың, Шәрифә?

– Апа, диген, мәнсез! Мин вчүтеки синнән ике яшькә зуррак, – диде кыз, кулын йолыккалап. – Җибәр, синең бармакларың тимер кебек каты.

– Минем өчен үлмәкче идеңмени, Шәрифә?

– Кем әйтә? Уф, менә хәзер мин егылып үләрмен бугай. Сафринә саескан очырдымы? Ул алдакчыга ышансаң, күкре каенга терәтер. – Шәрифәнең аксыл йөзен тимгел-тимгел бизәкләр чуарлады. – Нәстә миңа бәбәгеңне тасрайттың?! Тилебәрәннең төмен татыдым, вәйт шул! Кичке уенда: «Әйдә биибез», – дип эндәш кенә, үтерәм! Хуш, энекәш!

Озын толым, аккош муенын сузып, тыкрыктан «йөзеп» китте. Җенең сөймәү шушыдыр, мөгаен. Олы егетләр белән болай дорфа сөйләшми кызлар. Могҗиза иясе: «Яшеңне арттырыйммы?» – дисә, Нурихан бишкуллап ризалашыр иде. Югыйсә буй да озын, басудагы сирәк ужым кебек мыек та төрткән...

Бәрәкәтле урманга юл әрчелгән иде, хатын-кызлар, кояш белән бергә уянып, табигать нигъмәтләренә ашыкты. Тиздән тирә-як базарларны Наратлык бичәләре яулаячак иде.

Миннехан аучы, урман тарафларына күз ташлап:

– Хуп, – диде. – Хуп.

Әтисенә рәнҗегән үсмер эченнән генә: «Әйе, сиңа хуп», – дип мыгырдады. Ауга ияртмәде кирәбеткән ата! Бүген авыл Нуриханны тетеп мактар, бүген Шәрифә аның белән биер өчен иң матур күлмәген кияр иде.

– Ат җик әле, улым, – диде Миннехан. – Алатыр почмагына дәү капкын беркеткән идем. Бүрегә дип. Кирәге дә чыкмады үзе. Аулагын аулак, ул тирәләрдә кеше-фәлән дә болганмас, шулай да барып алыйм. Сакланганны саклармын, дигән Ходай.

Үсмернең ике күзе ут янды.

Аңа да бүре эләксә?!

Батырлык эшләргә беркайчан да соң түгел. Нурихан бүре тоткан, диячәкләр бит!

– Ерткыч көтүе белән чуаш урманнарына олакты, улым, – диде аучы, горурланып. – Билалетдин миңа теш кайрыйдыр. Ул бүкәнгә урман тапталмасын, агач туралмасын. Наратлык баяры!

Әтисе белән Билалетдин арасыннан йөгергән кара мәченең эзләре тирәнәя иде. Миннехан көндәшенең җыендагы галәмәтләрен мыек очына чорнаган, һаман шуны әрнеп-сызланып искә төшерә иде. Ә алга таба хәлләр тагын да катлауланды. Монысын инде берничек тә төзәтеп булмый, монысы дошманнарны маңгайга-маңгай чәкештерде. Капкын барыбер корбан сораган: Билалетдин аңа аягын кыстырган иде. Кирәк бит Алатыр почмагындагы чытырманлыкта буталып йөрергә!

– Арбага яткызып кайттым. Кирелләнде, бүлнискә илттермәде, – диде әтисе. – Каны күп аккан. Их, корт чаккыры, кешесе туры килүен күр син!

Кешесе кеше түгел иде шул. Билалетдин кич белән хәл белергә кергән әтисен бусагасыннан да атлатмаган:

– Терелсәм, мин сине авылдан сөрәм, ерткычлар газраиле, – дигән.

Миннехан аучы, Наратлыктан куылудан битәр, бүре капкынына кеше эләгүенә борчыла һәм моны ачыктан-ачык сиздереп:

– Их, корт чаккыры, ничекләр ялгыштым соң! – дип, бармагы белән маңгаена чүки иде.

Ә Нурихан эчтән сызды: ул әнә Шәрифәне югалтты... Кыз куралмауның соңгы дәрәҗәсенә җитте бугай, кичке уеннан да бизде. Сафринә исә, форсаттан файдаланып, тилгән кебек егетне сагалый иде. Ул төнге урамның кайсыдыр тыкрыгыннан тып итеп каршыга чыга да калку күкрәген егеткә китереп тери:

– Кочакла инде, аучы малае! Тилмертмә инде...

Нурихан сүзсез генә Сафринәне юл кырыена бастыра да эре-эре адымнар белән караңгылык эченә томырыла. Ә артыннан барыбер үзәк өзгеч сүзләр куып җитә:

– Шәрфә сине яратмы-ый!

Әнә күзе хәтле бәла, зурая-зурая, дөя хәтле хәсрәткә әверелә икән: Билалетдин чиреннән мантымыйча үлеп китте. Кабер казырга барган атаны ирләр зиратка кертмәде:

– Син Билалетдин белән гадел исәп-хисап ясамадың, хәрәмләштең! – диде мулла. Әйтерсең капкын ниндидер мәкер белән нәкъ менә урманчыга атап куелган иде.

Миннехан аучы акланмады, көрәген улына сузып:

– Абзаңнарга булыш, – диде.

Көнозын үсмернең колак төбендә мулланың кисәтүе яңгырады: «Гадел исәп-хисап ясамадың, хәрәмләштең!» Атаның урманчы белән сату-алуларда катнашканы да, уртак мал табып, үзара бүлешкәне дә юк иде.

Дәвамы бар >

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне уткәрeләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәрту, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 **ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ**

2 **ОНЛАЙН: vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.**

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

Сөенечле хәбәр!

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә ~~465 сум~~ **404,04 сум**

П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә ~~1000,92 сум~~ **859,08 сум**

6–16 декабрь көннәрендә ташламалы бәяләр!

Реклама 16+



«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ (843) 222-09-65, 222-09-70. E-mail: vtreklama@mail.ru

Мамадыш районындагы авыл

Бер дә, һич тә (иск.)

Себер шаманы

Әдәби әсәр бүлеге

«... маҗаралары» (Туфан Миңнуллин)

Җырлы-биюле уен

Татар телендәге килеш

Түбән сыйфатлы соры күмер

Татар халык җыры

Минвәлиев, Ваһ

Швейцария мәркәзе

Шарт теркәгече

Башкортстандагы шәһәр

Җырчы Закир ...

...-салон

Әмирхан ...

Тәбәнәк (ант.)

Җырчы ... Мон

Латвия каласы

Татарстандагы район

Куаклык, вак агачлык (диал.)

Сугылган башак

Башкортстандагы район

Төче су балыгы

Алма сорты

Бугаз

Нигер башкаласы

Башкорт биюе

Берләшү, туплану

Дейлның дусты

Камыр башы, ачыткы

Летка-... (фин биюе)

Актер Джеки ...

Тау күркәсе

Карак, бур

Рәис Габдулла

19 ноябрь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: Хуҗалар, Вахит, Раиса, кашу, таман, Умка, Карл, ату, Мата, куану, Ройс, Газиев, каян, корылма, абаз, ахры, гран. **Вертикаль буенча:** кепка, ашалу, обер, агора, Хәйруллина, ызан, узел, Җәвит, мурт, асау, арека, Хамматова, Али, Актай, танау, Сен.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Хәзерге Венгрияне элек ничек атаганнар?

А) Паннония;
Б) Речь Посполитая;
В) Пруссия.

2 Алтын Урда кайсы чорда чәчәк аткан?

А) XIV гасыр;
Б) XX гасыр;
В) XIV гасырның беренче яртысы.

3 Казан Кремле ЮНЕСКОның бөтендөнья мәдәни мирасы исемлегенә ничәнче елда кертелде?

А) 2000;
Б) 2005;
В) 2013.

4 Танылган хоккейчы Данис Зарипов үзенең спортчы буларак карьерасын кайсы командада башлый?

А) «Спартак»;
Б) «Мечел»;
В) «Звезда Чебаркуль».

Җаваплар: 1) А; 2) В; 3) А; 4) Б.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 17211 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 372

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73,
222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+